ТАТАРЧА ДӘРЕС

«ВТ» хәбәрчесе мәктәпләрдә туган тел һәм әдәбиятны ничек укытканнарын белеште.

> 5

КЫЙММӘТКӘ ТӨШӘ

Белгечләр социаль пакеттан баш тартмаска киңәш итә.

> 6

КУРКЫНЫЧ БУРЫЧ

Коллекторлар төнлә шалтыратса, янаса, җәза белән куркытса, нишләргә?

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 130 (29097) | Җомга | 8 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

«Татар-информ» / Владимир Васильев

ТӨТЕНСЕЗ ЮЛ

ЗАМАНА МАШИНАСЫНА КҮЧЕП УТЫРУ КҮПМЕГӘ ТӨШӘ?

Электромобиль! Әле кайчан гына мондый машина әкият кебек кенә тоела иде. «Тимер ат»ны төнгә утка тоташтырып калдырасың да иртән берни булмагандай рульгә утырып чыгып китәсең, имеш. Тик киләчәк турындагы кинолардан гына күреп белгән бу машиналар без уйлаганнан да тизрәк килеп җитте. Бүген Татарстанда шундый 450дән артык транспорт чарасы исәпләнә. Электромобиль бензин салып йөри торган машинага алмаш була аламы? Ул отышлымы? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

> 15

Ишетми калмагыз

Бу якшәмбе – 10 сентябрьдә Татарстанда Бердәм тавыш бирү көне узачак. Республиканың 36 районында җирле депутатларны өстәмә сайлаячаклар. 161 урынга барлыгы 545 кандидат дәгъва кыла.
Әйтергә кирәк, бердәм тавыш бирү көне зур сайлау циклын ачып җибәрә. Декабрьдә Россия Президентын сайлау игълан ителеп, киләсе елның мартында Президент сайлаячакбыз. 2024 елның көзендә – Бердәм тавыш бирү көнендә Дәүләт Советына сайлау үткәреләчәк. Ә инде 2025 елда Татарстан Рәисен, муниципаль депутатларны сайларга кирәк булачак. Цикл 2026 елда Дәүләт Думасына депутатлар сайлау белән тәгәлләнәчәк.

1 июньнән республикада су коенганда 53 кеше, шул исәптән 6 бала батып үлгән. Ел башыннан исә сулардагы 89 һәлакәт очрагында барлыгы 66 кешенең (8 бала) гомере өзелгән. Кешеләрнең харап булуының төп сәбәбе тиешсез урыннарда су керүгә бәйле. Нәкъ менә шуның аркасында 8 баланың гомере өзелгән. Җәй башыннан бирле Татарстанда тиешсез урыннарда коенган 64 кешегә штраф салынган.
Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре 65 кешене, шул исәптән 12 баланы үлемнән коткарып калган.

Татарстанда банклар узган елның мартыннан быелның июнь аена кадәр кредит каникулы турында закон һәм үзләренең программалары буенча 30 меңнән артыграк кредитның (барлыгы 13,7 миллиард сум) түләү вакытын үзгәрткән. 10 очракның 9ы банкларның үз программалары кысасында түләү графигын яңадан карау мөмкинлеген биргән.
«Кредит каникулы күпләргә түләүне туктатып торып, вакытлыча кыенлыкларны җиңү мөмкинлеге бирде. Бу тәҗрибә яңа закон әзерләүдә исәпкә алынды, – ди Россия банкының Татарстандагы бүлеге идарәчесе Марат Шәрифуллин. – Киләсе елның 1 гыйнварыннан даими кредит каникулы кертелә. Кредит түләвен ике очракта туктатып торырга мөмкин булачак. Беренчедән, кредит алучының кереме алдагы елдагыга караганда 30 проценттан күбрәккә кимесә. Икенчедән, кредит алучы гадәттән тыш хәл – авария, һәлакәт, табигать афәте аркасында зыян күрсә».

Киләсе атнада Татарстанда әбиләр чуагы башланыр кебек. КФУ профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев «Татар-информ» агентлыгы хәбәрчесенә әйтүенчә, хәзер кыска вакытлы суыту күзәтелә. Бу илнең Европа өлешенең төньяк циклон тәэсирендә калуына бәйле. Арктикадан суык һава агымнары үтеп кереп, явым-төшемгә китергән. Әмма озакламый һава торышы үзгәрәчәк.
Профессор сүзләренә караганда, инде якшәмбе – дүшәмбедән үк һава температурасының күтәрелүе көтелә.

НАМУС АКЧАДАН КЫЙММӘТ

8 сентябрь – Финанс хезмәткәрләре көне. Һөнәри бәйрәмнәре уңаеннан әлеге өлкә хезмәткәрләрен һәм ветераннарны Премьер-министр Алексей Песошин котлады.

«Татарстан Хөкүмәте һәм шәхсән үз исемемнән һөнәри бәйрәмегез – Финанс хезмәткәрләре көне уңаеннан котлыйм! – диелә котлауда. – Финанс системасы гомер-гомергә җәмгыять тормышында бик мөһим роль уйнап килә. Икътисадның барлык өлкәләренең тотрыклы үсүе, социаль әһәмиятле программаларны тормышка ашыру, халыкның тормышын яхшырту аның ни дәрәҗәдә нәтиҗәле эшләвенә бәйле.

Финанс дисциплинасы, бюджетара мөнәсәбәтләрдәге тотрыклылык, чыгымнарның нәтиҗәлелеге – сез һәр көн саен уңышлы төстә үтәп килгән төп бурычлар бу. Шуның нәтиҗәсендә Татарстан теләсә кайсы кыенлыкларны җиңеп чыга.

Республикабыз финансистларының югары дәрәҗәдәге һөнәри осталык һәм намуслылык кебек сыйфатлары белән аерылып торачагына ышанам.

Хезмәтегез өчен, эшкә намуслы мөнәсәбәтегез өчен рәхмәт! Сезгә һәм гаиләләрегезгә нык сәламәтлек, бәхет, иминлек, уңышлар телим!»

ВАКЫТ КҮРСӘТЕР

Республиканың тулай төбәк продуктының дүрттән бере диярлек казылма байлыкларга туры килә.

Бу хакта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында узган утырышта әйттеләр. Чарада 2024–2026 елларда республиканың социаль-икътисадый үсешенә бәйле фаразлар, 2024 елга һәм планда каралган 2025, 2026 елларга республика берләштерелгән бюджеты һәм Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты фаразлары кебек мәсьәләләр каралды.

7 ай нәтиҗәләре буенча республикада тулай төбәк продукты 2 трлн 176 млрд сумга җиткән. Бу – узган елгы күрсәткечләргә карата 104,7 процентны тәшкил итә. Сәнәгать җитештерүе индексы – 103,8 процент, ә төяп озатылган продукция күләме – 2,5 трлн сум.

Рөстәм Миңнеханов әлеге юнәлешләрдә зур эш башкарылуын искәртте. Агымдагы ел нәтиҗәләрен уңай бәяләде. Киләсе ел бюджетын формалаштыру турында әйткәндә, район башлыкларына мөрәҗәгать итеп, артык җәелеп китмәскә дә киңәш итте. «Безнең төп бурыч – икътисадның эшен тәэмин итү», – диде Татарстан Рәисе.

2023 елга икътисадый фаразлар

(миллиард сумнарда)

тулай төбәк продукты күләме	**3887,4**
сәнәгать күләме	**4490,8**
авыл хуҗалыгы	**292,3**
төзелеш	**643,3**
ваклап сату	**1313,0**
инвестицияләр	**959,9**
төяп озатылган продукция күләме	**4490,8**

2024 елда ул – 4721,9, 2025 елда – 5104,0, 2026 елда 5379,8 миллиард сум дәрәҗәсендә фаразлана

Киләсе елларга бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәре буенча фаразлар

2024 ел	**377,1**
2025 ел	**396,6**
2026 ел	**422,6**

Киләсе елларга тупланма бюджетның гомуми чыгымнары буенча фаразлар

2024 ел	**397,4**
2025 ел	**418,9**
2026 ел	**451,7**

Бер көндә – ике утырыш

Дәүләт Советында парламент Президиумы утырышы узды. Анда алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының берьюлы ике утырышын үткәрү турында карар кабул ителде. Президиум утырышын Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин уздырды.

Парламентның көзге сессиясе 14 сентябрьдә Сәйдәш исемендәге Дәүләт Зур концертлар залында кырык алтынчы утырыш белән башланып китәчәк. Иртәнге сәгать 10да Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Дәүләт Советына еллык Юллама белән чыгыш ясаячак. Шул ук көнне сәгать 12дә Дәүләт Советында парламентның кырык җиденче утырышы башлана.

Кырык алтынчы утырышның көн тәртибендә бер генә мәсьәлә – Татарстан Рәисенең республиканың эчке һәм тышкы хәле турында Дәүләт Советына еллык Юлламасы күздә тотылган.

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина билгеләп үткәнчә, кырык җиденче утырышның көн тәртибенә комитетлар тәкъдиме белән 18 мәсьәлә, шул исәптән 12 республика законы проекты һәм бер федераль закон проекты кертелгән.

Парламентчылар кырык җиденче утырыш кысасында шулай ук югары белем бирү оешмаларының спорт-савыктыру лагерьларын төзекләндерү турында Россия фән һәм югары белем министры Валерий Фальковка Дәүләт Советы мөрәҗәгатен карап тикшерәчәк. Утырышта депутатлар 2022 елда Татарстанда мәгарифне үстерү программаларын тормышка ашыру турында Министрлар Кабинеты мәгълүматын да тыңлаячак. Әлеге тема буенча мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллинның чыгышы көтелә. «Хөкүмәт сәгате» кысасында исә мәдәният министры Ирада Әюпова матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында республика законын гамәлгә ашыруның барышы хакында сөйләячәк.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарлары 19 нчы биттә >

ЯХШЫ НИЯТ – ЭШ БАШЫ

Казанда – яңартылган яр буе, Әлмәттә – кино-концерт залы, Алексеевскида – кунакханә. Татарстан Министрлар Кабинетында Инвестиция советының чираттагы утырышы узды. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка 43,4 миллиард сумлык тугыз проект тәкъдим иттеләр.

– Бу елның алты аенда республикага инвестиция кертемнәре 385 миллиард сум тәшкил итте, – диде Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина. – Төбәкнең төп капиталына җәлеп ителгән инвестицияләр үсеше – 116 процент. Шул исәптән 327 миллиард сумы – шәхси инвестицияләр. Сәяси, икътисадый вазгыятьне исәпкә алганда, бу – бик яхшы саннар.

Күрсәткечләр тагын да үсәчәк. Инвестиция советы утырышында тәкъдим ителгән тугыз проект та яклау тапты.

1 Арада иң кыйммәтлесен Казанда тормышка ашырырга җыеналар. Казансу ярында, тәгаенрәк әйтсәк, «Ривьера» күңел ачу комплексы күршесендә өр-яңа ял һәм эш үзәге калкып чыгачак. Әлеге проектны тормышка ашырачак «KravtGroup» оешмасы генераль директоры Валерий Кравцун сүзләренә караганда, әлегә Татарстанда яңа төзеләчәк күпфункцияле үзәккә тиңнәр юк. Казансу ярында биш йолдызлы кунакханә, биш мең кешегә исәпләнгән конгресс-үзәк, кибетләр, егермеләп ресторан, төзекләндерелгән яр буен берләштергән комплекс төземәкчеләр.

– Бу – безнең республикадагы өченче проект, – диде Мәскәү оешмасы җитәкчесе. – Тәүге кунакханәне аэропорт янында төзедек. Бу ел ахырында Иннополиста кунакханә төзеп бетерергә ниятлибез. Казансу ярында тормышка ашырылачак проектның инвестиция бәясе 29 миллиард сумга якын тәшкил итә. Гомумән, Татарстанны инвестицияләр җәлеп итү өчен иң яхшы урын дип саныйм. Республика җитәкчелеге дә безгә даими ярдәм күрсәтә.

2 Әлмәттә республика нефтьчеләре ярдәме белән кино-концерт залы төзеләчәк. Инвестиция проектын «Татнефть» тәкъдим итте. Концерт залы үзе генә дә 1100 кешегә исәпләнгән. Моннан тыш, биредә ике кинозал, ресторан да булачак. Инвестиция күләме 12,6 миллиард сум тәшкил итә.

– Без социаль проектлар белән даими рәвештә шөгыльләнәбез, – диде «Татнефть» генераль директоры урынбасары Николай Глазков. – Әлмәттә төзеләчәк кино-концерт залына, концерт залының акустикасына ил күләмендә дә тиңнәр булмаячак. Биредә орган да урын алачак. Проектны 2026 елга кадәр тормышка ашырырга ниятлибез.

3 Алексеевск районында кунакханә төзеячәкләр. Аның урынын да сайлаганнар инде. Ул «Казан – Оренбург» федераль трассасы янәшәсендә, Алексеевск бистәсенә кергән юлда булачак. Инвестиция күләме – 205 миллион сум.

4 Туризмга бәйле тагын бер проектны Яшел Үзәндә тормышка ашырырга ниятлиләр. Кызыл Кармыш авылы янында ял базасы төзеләчәк.

5 Чаллыда исә эш урыннары артачак. Автокалада тагын бер завод пәйда булачак. Биредә спорт һәм актив ял итү өчен техника җитештерүне җайга салмакчылар. Мәсәлән, спорт автомобильләре, электр кар чаналары, балыкчылар һәм аучылар өчен махсус чаналар чыгара башлауны күздә тоталар. Заводны тулы куәтенә 2030 елда ук эшләтеп җибәрергә ниятлиләр. Инвестицияләр күләме 108 миллион сум тәшкил итә.

6 «БарсАвто» МАЗ, Урал, Hawo, SITRAK, Izuz, DONGFENG, JAC, КАМАЗ йөк автомобильләре өчен борт платформалары җитештерүне җайга салмакчы.

7 Чистайда төзелеш катнашмалары әзерләү өчен җайланмалар җитештерергә ниятлиләр.

8 «Лаеш» индустриаль паркы мәйданчыгында электроника һәм робототехника җиһазлары җитештереләчәк.

9 Утырышта «Анатомика» ширкәтенең «Бот сөяге буын эндопротезлары җитештерү» проекты да хупланды.

«Татар-информ»

БЕРЕНЧЕ ҖЫЕН

Башкалада «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» халыкара форумы эшли башлады. Тәүге тапкыр үткәрелә торган чарада илнең 57 төбәгеннән һәм 24 чит илдән 5,5 меңгә якын кеше катнаша. Беренче коймак төерле түгел: җыенны киләсе елда да үткәрмәкчеләр. Аның көне дә билгеле инде.

– Кытайдагы хезмәттәшләребезнең безнең тәкъдимне кабул итеп алуларына сөендек, – диде Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов форумның ачылыш тантанасында. – Россия һәм Кытай Халык Республикасы башлыкларының шәхси тырышлыгы нәтиҗәсендә төбәкара хезмәттәшлекне үстерү өчен дә яхшы мөмкинлекләр булдырылган. Якын арада хәл ителәчәк мөһим бурыч – яңа шартларда җитештерү өлкәсенең тотрыклылыгын арттыру. Кытай куелган максатларга ирешүдә ышанычлы партнер булып тора.

Рәис әйтүенчә, форумны биредә катнашучы һәр кеше өчен кызыклы һәм файдалы булырлык итеп оештырырга тырышканнар. Җыенның эшлекле программасы 11 тематик юнәлеш буенча 40лап сессияне үз эченә ала.

– Алар икеяклы хезмәттәшлекнең иң актуаль һәм кискен мәсьәләләренә кагыла. Форумда шулай ук катнашучылар өчен «Russia – China Expo» күргәзмәсе дә оештырылган. Анда Россия һәм Кытайның эре инвестиция һәм инфраструктура проектлары, шулай ук машина төзелеше һәм металл эшкәртү комплексы оешмалары тәкъдим ителгән. Россия кулланучылары өчен Кытай автомобиль сәнәгатенең күптөрлелеген һәм югары потенциалын чагылдыручы күргәзмә дә бар. Көнбатыш партнерларга бәйле чикләүләр шартларында Кытай автомобильләре лаеклы урын алып тора һәм аларга ихтыяҗ зур, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Кытай «тимер ат»ларын Рәискә дә күрсәттеләр. Ул кунаклар белән бергә халыкара күргәзмәне карады. Аерым алганда, биредә «Татнефть», «СИБУР», «ТАИФ-НК» компанияләренең ерактан ук игътибарны җәлеп итүче зур стендлары урын алган иде. Казан милли тикшеренү технология университетына керүче «Союзхимпроект» проект институты вәкилләре исә Рөстәм Миңнехановка Кытай вузлары белән хезмәттәшлек турында сөйләде. Алга китеп булса да әйтик, Татарстан вузларында белем алучы чит ил студентлары арасында Кытай өченче урында тора. Бу хакта «РОСТКИ» халыкара форумы кысасында узган матбугат очрашуында Татарстан мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Андрей Поминов әйтте. «2022/2023 нче уку елы мәгълүматларына караганда, республикада Кытайдан 1896 студент белем алган. Кытай студентлары саны буенча беренчелек – КФУда. Икенче урында – Казан дәүләт консерваториясе. Беренче өчлеккә КНИТУ-КАИ да эләккән», – дип сөйләде ул журналистларга.

Күргәзмәгә әйләнеп кайтсак, аның зур өлешен Кытай автомобильләре алып тора. Биредә егермеләп чит ил машинасы тәкъдим иттеләр. Рөстәм Миңнеханов аларның кайберләренә утырып та карады.

Кытайның Россиядәге илчелегенең сәүдә-икътисадый мәсьәләләр буенча киңәшчесе Юй Хунчи әйтүенчә, быелның гыйнварыннан июленә кадәр Россия белән Кытай арасында товар әйләнеше 134 миллиард доллар тәшкил иткән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, күрсәткеч 36,5 процентка үскән.

– Соңгы елларда Россия һәм Кытай башлыкларының стратегик җитәкчелеге бәрабәренә безнең хезмәттәшлек яңа үсеш алды. Кытай инде 13 елдан бирле Россиянең төп сәүдә партнеры булып тора, – диде ул.

Юй Хунчи сүзләренә караганда, соңгы елларда Кытай белән Татарстан арасында да сәүдә-икътисадый хезмәттәшлек тотрыклы үсә. Былтыр сәүдә күләме 1,6 миллиард долларга җиткән.

– Татарстанда сәнәгать, авыл хуҗалыгы зур үсеш алган. Бу предприятиеләргә көнкүреш техникасы җитештерү, автомобильләр җыю, җиһазлар сатуда хезмәттәшлек итәргә шартлар тудыра, – диде Юй Хунчи.

Эшлекле сөйләшүләр көне буе дәвам итте. Рөстәм Миңнеханов «Чжэньвэй» халыкара күргәзмә корпорациясе җитәкчелеге белән очрашты. Әлеге корпорация Кытайның иң эре шәхси күргәзмә компаниясе булып санала. Ул ел саен йөзгә якын халыкара махсуслаштырылган күргәзмә һәм зур чаралар оештыра.

– Кичә самолеттан төшкәч, беренче күргән нәрсә «Казан Экспо» күргәзмә үзәге булды. Без, бу өлкәдә профессионаллар буларак, шунда ук аның логистик яктан бик дөрес урнашканын билгеләп үттек, – диде Кытай күргәзмә корпорациясе президенты Дэн Сяохуэй.

Форум кысасында «Kangrun Group» генераль директоры Ван Гуймин һәм «Hynovation» компаниясе вице-президенты У Гопин белән очрашу барышында Рөстәм Миңнеханов хезмәттәшлекне тирәнәйтү мөмкинлекләре турында әйтте.

– Кытай безнең республикага һәрвакыт кызыклы булды. Пандемия чорында килеп чыккан кыенлыкларга карамастан, Кытай эшкуарларының – безнең базар белән, Россия бизнесының Кытай белән кызыксынуын күрәбез. Татарстан компанияләре шулай ук Кытай базарын һәм Кытай технологияләрен игътибар белән күзәтә, – диде Рөстәм Миңнеханов Кытай эшкуарлары берлеге рәисе Чжоу Лицюнь белән очрашканда.

Россиядә Кытай эшкуарлары берлеге 2006 елда оешкан. Ул безнең ил базарында эшләүче Кытай бизнесының күпсанлы вәкилләрен берләштерә. Рөстәм Миңнеханов ассызыклаганча, Берлек Кытай һәм Россия бизнесын тоташтыручы күпер булып тора, шулай ук икътисадый кооперациягә ярдәм итә.

Рәис «Sany Group Company» Кытай компаниясе вәкилләре белән очрашты. Әңгәмә барышында яклар Татарстанда «Sany» җитештерүен үстерү мөмкинлеге турында фикер алыштылар.

CHN Energy (Кытай) халыкара үсеш компаниясе Директорлар советы рәисе У Цюан белән очрашу барышында кунаклар республиканың энергетика һәм сәнәгать потенциалын югары бәяләде һәм хезмәттәшлекне үстерүгә кызыксыну белдерде.

Җыенда Рөстәм Миңнеханов Россия – Кытай халыкара форумын ел саен үткәрү теләген дә җиткерде.

– Киләсе елга форумның датасын 14–15 ноябрьгә билгеләргә тәкъдим итәбез һәм Кытайдагы хезмәттәшләребезне икенче Халыкара форумда түземсезлек белән көтәбез, – диде ул.

Әйткән сүз – аткан ук: Татарстан Сәүдә-сәнәгать палатасы рәисе урынбасары Марат Әхмәтов форумның беренче көненә йомгак ясаганда, аның уңышлы мәйдан булуына ишарәләп, киләсе елда җыен өч тапкыр зуррак узачак, дип фаразлады. Форум бүген тәмамлана.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Замана таләбе

«Kazan Digital Week – 2023» форумында көн кадагында торган сорауларга фикер алышачаклар

Татарстан башкаласында узачак «Kazan Digital Week – 2023» халыкара форумы чын мәгънәсендә акыл сату мәйданчыгына әверелмәгәе. Оештыручылар әйтүенчә, бирегә бөтен ил җыелачак. Җыелып кына калмыйча, заманча технологияләр һәм аларны көндәлек тормышта, бизнеста, дәүләт идарәсендә куллану ысулларын барлаячаклар. Форум 20–22 сентябрьдә «Казан Экспо» үзәгендә узачак.

Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин әйтүенчә, форумның төп темасы – импортны алмаштыру. Гомумән, әлеге чарада 10 төп юнәлеш каралачак. Мәгариф, мәдәният, сәламәтлек тармаклары да читтә калмаячак, киберкуркынычсызлык, мәгълүмати технологияләр хакында да сүз булачак. Эшлекле программа кысасында 107 секция, «түгәрәк өстәл» һәм 5 конференция узачак.

Мәгълүм булганча, быел форум яңа статуста – федераль дәрәҗәдә уза. Оештыру комитетын җитәкләгән Россия цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры Максут Шадаев әйтүенчә, әлеге форум төбәкләрдә уза торган иң зур чараларның берсенә әвереләчәк.

– Иң мөһиме – форум мәйданчыгында тәҗрибә уртаклашырдай җитештерүчеләр, уйлап табучылар очрашачак, – диде министр.

Аның әйтүенчә, быел форумга теркәлгән катнашучылар саны узган елгы күрсәткечләрдән ике тапкыр күбрәк. Димәк, чарага карата кызыксыну да, ихтыяҗ да юк түгел.

Татарстан Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов форум кысасында узачак кызыклы чаралар турында хәбәр итте. Әйтик, студентларның киберкөрәше көтелә. Моннан тыш форумның тематик юнәлешләренә караган иң яхшы проектлар «IT лидер» бәйгесендә катнашачак. Иң күп тавыш җыйган һәм экспертлар бәясен алган проектларны форум азагында бүләкләячәкләр.

Форум – саннарда

5742 кеше

Шулар арасында **1111** спикер,

4631 катнашучы

253 фәнни мәкалә

31 ил

4 мең кв. м күргәзмә мәйданы

133 стенд

378 кв. м стартаплар өчен

500 кв. м мәйданда урам күргәзмәсе

Әйтеп кенә бактым

БӘРӘЗӘ МАӘМАЕ

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Күптән түгел сабакташыбыз, язучы, шагыйрь, журналист Рашат Низамиевны, васыятьнәмәсе буенча, хатынының авылы Бәрәзәдә җирләдек. Арабыздан көтмәгәндә китеп барды ул, бакчасында эшләп йөргән җирдән үлеп киткән.

Тагын бер сабакташым, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров белән Бәрәзәгә барып җиткәнче, Рашат дусны җир куенына куйганчы вафатына ышанмадык без аның.

Зират эченә кергәнче Рашат яткан колашаны җиргә куйдылар да хәзрәт укый башлады. Без йоласын китереп, рәт-рәт басып, имамга оеп торабыз. Шулвакыт минем янга аклы-сарылы кечкенә генә бер эт килеп басты. Моңсу күзләрен күтәреп миңа карап алды да, хәзрәткә текәлеп, тынып калды.

Хәзрәт укып бетерде, хатын-кызларны койманың тышкы ягында калдырып, зират эченә атладык. Эт тә башын иеп безгә иярде. Тегендә-монда йөгереп йөрмәде, тавыш чыгармады. Рашатны җирләгәндә этне беравык күздән югалтып тордым. Инде яңадан дога укырга әзерләнгәч, минеке кебек аяклары авыртканнар өчен куелган эскәмия янына килеп арт аякларына утырды бу. Хәзрәт укый башлагач, кешенеке кебек акыллы, моңлы күзләре белән янә миңа карап алды да, гафу үтенгәндәй кыяфәт чыгарып, үләнгә сузылып ятты да әкрен генә күзләрен йомды.

Сәер иде аның үз-үзен тотышы. Әйтерсең лә имамга оеп, безнең белән дога укыды. Хәзрәт укып бетергәнче тынын да чыгармады. Дога тәмамланып, без бераз кыймылдаша башлагач, әкрен генә күзләрен ачты, аннан торып утырды һәм безгә ияреп зираттан чыкты. Акыллы, мәгънәле карашы белән безне озатып калды.

Соңгы вакытларда мин мистикага тартым хәлләргә еш очрый башладым. Бәрәзәнең бу сәер эте белән очрашу да шундый хәлләрнең берседер дип кабул иттем. Өйгә кайткач та күңелем тынычлык тапмый интекте. Аптырагач, сабакташым Зиннурга шалтыраттым. Әткә ул да игътибар иткән икән. «Язарга уйласаң, сиңа бер гыйбрәтле язма җибәрәм, кирәк тапсаң, файдаланырсың», – диде. 1947 елда язылган, архивтан алынган хат иде ул. Кыскача эчтәлеге мондыйрак. Себергә сөрелгән дин әһелләрен Воркутага шахта төзергә җибәрәләр. Алар арасында абыйлы-энеле ике мулла да була. Җомга көнне намаз укыганнары өчен лагерь хуҗасы, сакчыларга әйтеп, аларны гел кыйната торган була. Инде муллалардан тәмам котылырга теләп, бер җомга көнне боларны этләрдән талаттырырга ниятли. Махсус ач тотканга, тәмам ерткычка әйләнгән алты этне бәйдән ычкындырырга куша. Үзләренә таба чабып килгән этләрне күргәч, муллалар аларга каршы борылып баса да, кулларын югары күтәреп, дога укый башлыйлар. Шунда көтелмәгән хәл була: ике бертуган янына килеп җиткәч, этләр өрүдән туктый, койрыкларын болгап, чиный-чиный муллалар тирәсендә әйләнеп йөриләр дә аларның аякларын ялый башлыйлар. Бу хәлне күргәч, тоткыннар гына түгел, сакчылар да елап җибәрә.

Хаттагы соңгы җөмләләрне үзгәртми-нитми генә күчереп язарга булдым. «Бөек көч бар! Тырыша-тырыша Аның юклыгын исбатларга омтылсалар да, Ул бар!»

Мин дә, Зиннур да илаһи көч барлыгына ышанабыз. Җомга көнне бакыйлыкка күчкән кеше турында «бәхетле үлем белән үлгән» диюләренә дә ышанабыз. Үлем турында «бәхетле» дип әйтү сәер тоелса да, җомга көнне вафат булган Рашат рухына укылган догаларыбызның барып җитәсенә, авыр туфракларын җиңел итәчәгенә, дустыбызның урыны җәннәт бакчаларының түрендә булачагына да ышанабыз.

Ә Бәрәзә маэмаена килгәндә, аның үз-үзен шулай тотуы минем өчен һаман да сер булып кала әле.

КИЛЕШҮЛӘР ТУРЫНДА КИЛЕШҮ

kremlin.ru

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

4 сентябрьдәге Путин – Әрдоган очрашуын Россия җәмәгатьчелеге дә, дөньякүләм сәясәтчеләр дә зур кызыксыну белән көттеләр. Саммит, чынлап та, интригалы булырга вәгъдә итте, чөнки, бердән, Россия демонстратив рәвештә чыккан «ашлык килешүе» кабат торгызылырга тиеш, икенчедән, инде ел ярымнан артыкка сузылган Украинадагы конфликт сөйләшүләр өстәле янында хәл ителә башламасмы дигән кечкенә генә өмет тә юк түгел иде.

Россия – Төркия арасындагы икътисадый хезмәттәшлеккә караган килешүләр дә көтелде, билгеле, алары да халыкара әһәмияткә ия, әмма беренче ике пункт игътибарны күбрәк җәлеп итә. Ике яклы сөйләшү бик тәфсилләп әзерләнде: ике илнең тышкы эшләр министрлары алдан очрашып сөйләштеләр. Дипломатларның андый очрашулары гадәттә имза салырлык документлар әзерләү белән тәгәлләнә. Шундый әзер кәгазьләр юк икән, лидерларның очрашуы нигә? Сочига Үзәк банк, Тышкы эшләр министрлыгы, Оборона министрлыгы җитәкчеләренең килүләре дә масштаблы карарлар кабул ителәчәгеннән дәлилли иде кебек. Киң җәмәгатьчелеккә игълан ителмәгән вакыйгалар сәхнә артында да барды.

Әмма... Путин – Әрдоган очрашуы бернинди килешүләрсез тәгәлләнде. Хәтта Кремль инициативасы булган газ хабы буенча да уртак документ имзаланмады. «Ашлык килешүе» һәм тынычлык турында сөйләшүләр хакында әйтеп тә торасы юк. Без саммитта эчке пружиналарның ничек хәрәкәтләнүен белә алмыйбыз, билгеле. Хәтта Әрдоган да Путин белән сөйләшү башында гаҗәпкә калды, диделәр. Кремль, күрәсең, дипломатик каналлар аша ирешелгән барлык килешүләрне берьюлы кире кагып, бөтенләй яңа тәкъдимнәр белән килгән. Очрашудан соң Әрдоганның социаль челтәрдә Путинны «кадерле дус» дип атавы ул тәкъдимнәрнең төрекләр өчен кызыктырырлык булуына ишарә итә. Ләкин аларны килешү дәрәҗәсенә күтәрү өчен тикшерәсе һәм өйрәнәсе бар. Путинның яңа тәкъдимнәр җыелмасын Украина һәм Көнбатыш белән дә килештерергә кирәк, эшнең ул ягы да мөһим. Бер мәсьәләдә генә төрек лидеры сүзне өзеп әйтте: «Тынычлык өчен өметләндерерлек перспективалар горизонтта күренми», – диде. Димәк, конфликтка кергән якларның якын арада тыныч сөйләшүләр өстәле янына утыруларын көтәргә кирәкми.

Путинның көтелмәгән яңа инициативалары төрек ягын канәгатьләндергән булырга тиеш, чөнки Әрдоган сөйләшүләрне «нәтиҗәле һәм продуктив» дип бәяләде. Күп кенә аналитиклар, төрек сәясәтенең карт төлкесе Сочига «ашлык килешүе» өчен дә, Украина конфликтын тыныч сөйләшүләр юнәлешенә кертеп җибәрү өчен дә түгел, ә Россия газын төрек лираларына сатып алу турында килешү өчен килде, диделәр. Һинд рупиясе белән килеп туган проблемалар Кремльне төрек лирасына сак карарга мәҗбүр итә, әлбәттә. 30 миллиард доллардан артыграк рупиянең Һиндстан банкларында эленеп калып, Россия өчен бернинди дә файда китермәве Мәскәүдә гаеплеләрне эзли башлауга этәрде дигән сүзләр дә йөри. Гомумән, милли валюталарда сәүдә итү Россиягә зур зыян сала. Доллар кыйммәтләнә, бу юллар язылганда, ул яңадан 98 сумлык үрне яулады. Үзәк банк 15 сентябрьдәге утырышында төп ставканы тагын күтәрәчәк, дигән хәбәрләр бар. Сум шикелле үк зәгыйфь һәм конвертацияләнми торган лираларга бәйләнү яңа зур югалтуларга китерәчәк. Әмма, бердән, Әнкараның бу өлкәдә Мәскәүгә басым ясау мөмкинлекләре шактый, икенчедән, газны кая куясың?

Әрдоган «ашлык килешүе» буенча Путинның яңа тәкъдимнәре кызыклы дип саный һәм якын киләчәктә килешүгә ирешергә өмет белдерә. «Ашлык килешүе» – Россия өчен сөйләшүләрнең умыртка баганасы ул. Украина ашлыгы ул килешүдә Россия өчен бернинди әһәмияткә дә ия түгел. Сатылмаса, яхшырак, чөнки ашлыкка бәяне күтәреп, Мәскәүгә өстәмә дивидендлар китерә. Килешү төзелә икән, Россия өчен файдалы булсын. Путин Россия ашлыгы һәм ашламасын экспортлауга киң юл ачылуны, Россельхозбанкны SWIFT системасына кушуны, Россиягә чит илдән авыл хуҗалыгы техникасы сатып алу мөмкинлеген бирүне, Россиядән Одессага аммиакүткәргечне торгызуны таләп итә. Бу таләпләр үтәлсә, Россия яртылаш санкцияләр богаусыннан чыкты, дип әйтеп булыр иде, әмма аларның үтәлешен Әрдоган гарантияли алмый. Эшнең бөтен катлаулы ягы шунда. Шуңа күрә әлегә Путин – Әрдоган сөйләшүләре килешүләр турында килешү белән генә тәгәлләнде. Төрек лидерының оптимизмына караганда, чын килешүләр дә кайчан булса да бер имзаланыр кебек. Путин таләпләре кысасында килешү була алса, доллар курсы һәм инфляция күрсәткечләре безнең кесәләр файдасына үзгәрер иде. Путин һәрбер чыгышында «Көнбатыш безне алдады» дигән тезисны алга сөрә. Бу юлы принципиаль катылык күрсәтергә тели. Әмма һәрбер килешү компромисслар таләп итә ул барыбер.

БЕРТИГЕЗ СОРАЯЧАКЛАР

ТАТАР МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕ КИМЕГӘН, ТАТАР ТЕЛЕ АРТКАН

Яңа уку елында мәктәпләрдә федераль дәүләт стандартының яңартылган федераль программасы буенча эшли башладылар. «ВТ» хәбәрчесе шул уңайдан мәктәпләрдәге туган телгә бәйле вазгыятьне белеште.

Узган уку елында республикада 610 татар мәктәбе эшләгән. Татар телендә белем алу күрсәткече – 25, белем һәм тәрбия бирү 51 процентны тәшкил иткән. Узган уку елында «Туган тел һәм әдәбият» предметлары кысасында укучыларның 63 проценты – татар, 36 проценты – рус телен һәм 1 проценты чуаш, мари, мордва, удмурт, иврит һәм башкорт телләрен өйрәнгән. Яңа уку елында укучыларның күпмесе туган тел буларак, татар һәм башка телләрне сайлавы әлегә билгеле түгел. Моны сентябрь ахырында белербез.

Тагын уйга калдык...

Татар теленнән федераль эш программалары төзүдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре катнашты. Институтның милли мәгариф бүлеге мөдире Гөлназ Мөхәрләмовадан моның нечкәлекләре турында сораштык.

Гөлназ Мөхәрләмова белдергәнчә, бердәм программага нигезләнгән дәреслекләр кертелү укучыга кайда һәм нинди шартларда белем алуына карамастан, бер югарылыкта, бер дәрәҗәдә белем алу мөмкинлеген тудыра. Төрле бәйгеләрдә, олимпиадаларда, ниһаять, югары уку йортларына кергәндә сынаулар да, аз да түгел, күп тә түгел, нәкъ шул күләмдәге белемне таләп итәчәк.

– Федераль белем бирү программаларының бер өлеше булган «Туган тел (татар теле)» һәм «Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметлары буенча федераль эш программаларына берникадәр үзгәрешләр кертеп эшләргә туры килде, – диде Гөлназ Мөхәрләмова. – Яңа уку планнарына игътибар итсәк, татар мәктәбенә караган өлештә сәгатьләр санында үзгәрешләр бар. Әгәр элек татар телен өйрәнүгә – 2 сәгать, әдәбият фәненә 2 сәгать бирелгән булса, яңа планнарда сәгатьләр бүленеше татар теленә – 3 сәгать, әдәбиятка 1 сәгать бирелә.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына әдәбият укыту бер сәгатькә калгач, бер борчылган булсак, хәзер инде татар мәктәпләрендә халкыбызның бай әдәби мирасын бер сәгать эчендә ни рәвешле сыйдырып бетереп укытып булыр икән дип тагын уйга калдык.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнгән туган тел (татар теле) дәреслекләре (авторлары – М. Шәкүрова, Л. Гыйниятуллина, О. Хисамов) һәм туган (татар) телдәге әдәбият дәреслекләре дә (авторлары – Д. Абдуллина, Г. Мөхәрләмова) федераль эш программаларына туры китереп, заман таләпләренә, филологик һәм педагогик белемнең яңа алымнарына туры китереп эшләнгән.

Эшләп карагач, беленер

Балтач районының Куныр мәктәбендә хәзер 3 сәгать – татар теле, 1 сәгать әдәбият укытылар. Татар теле укытучысы Әнисә Саттарова белдергәнчә, баланы китаптан бөтенләй биздермәс өчен, укытучыга тырышырга туры киләчәк. Сүз уңаеннан, быел республикада 8 укучы татар теленнән бердәм республика имтиханы тапшырган иде. Алар арасында Әнисә Саттарованың укучысы Зилия Юнысова да бар. Ул КФУда татар теле юнәлешен сайлаган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Яңа дәреслекләр безгә бик ошады», – ди татар теле укытучылары.

– Әдәбият дәресләренең кыскаруы борчый, әлбәттә. Балаларга әсәрне укып кына түгел, күңелләренә барып җитәрлек итеп сеңдерергә кирәк бит. Кызыксындыру юллары эзлибез. Сканвордлар төзергә тырышабыз. Узган ел 5 нче сыйныфларга татар телен яңартылган стандартлар нигезендә төзелгән электрон кушымта ярдәмендә укыттым. Менә шуны дәреслек итеп бастырсалар, бик әйбәт булыр иде. Анда әдәбият белән дә бәйләнеш бар, – ди 28 ел татар теле укытучы Әнисә Саттарова.

Гөлгенә Нурмиева исә Казандагы 27 нче татар гимназиясендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Аның әйтүенчә, әлегә ана теле укытучылар яңа программага үзләре дә төшенеп кенә килә. Ни өчен дигәндә, дәреслекләр белән программалар арасында аерма зур. Эшләп карамыйча, уңай һәм тискәре ягын әйтә торган түгел. Элеккегесе белән чагыштырганда, укытучыга, балаларның белемен бәяләүгә карата таләпләр төгәлләштерелгән. Үзгәрешләр сәгатьләр санына кагылган. Татар теле 1 сәгатькә арткан. Бу һәр мәктәптә төрлечә.

– 5 нче сыйныфка яңа татар теле дәреслекләре (авторы – М. Шәкүрова) кайтты. Хәзер әдәбиятны көтәбез. Бу дәреслеккә сынау үткәргән идек. Укучыларга бик ошады. Анда тәрбия беренче урынга куелган. Хәзерге заман таләпләренә туры килә торган электрон кушымтасы да бар, – ди Гөлгенә Нурмиева.

– Бердәм дәреслекләргә күчү бара. Татар мәктәбе булгач, безнең сайлау мөмкинлеге әллә ни зур түгел иде. Гомер буе бер дәреслек белән эшләргә күнектек. Бәлкем, рус төркемнәре өчен үзгәреш бардыр. Сыйныфларда бер генә дәреслек линиясе бармый иде. Бу исә бер сыйныфтан икенчесенә күчкәндә йогынты ясамыйча калмый. Әйтик, бишенче сыйныфта – бер, алтынчыда – икенче төрле. Әгәр бер автор яки авторлар төркеме булса, белемне системага салырга ярдәм итәчәк.

Дәресләр кыскармый, дәреслекләр юкармый

Татарстан Мәгариф министрлыгының милли мәгариф бүлеге башлыгы Энҗе Гыйзәтуллина, мәктәпләрдә сәгатьләр саны да узган елдан үзгәрмәде, дип белдерде. Туган тел, гадәттәгечә, әти-әниләр гаризасы буенча сайлана. Закон буенча укыту планын мәктәпләр үзе төзи һәм раслый. Бездә туган тел укытылмаган мәктәп юк. Россия буенча исә туган тел булмаган укыту планнарын да керткәннәр.

– Федераль программаларның максаты – бердәм белем бирү киңлеге булдыру. Моңа кадәр һәр дәреслек авторының үз программасы булса, хәзер дәреслекләр бер программага нигезләнеп төзеләчәк. Татар теленнән бердәм программаларны төрле дәреслек авторлары бергәләп төзеде. Бу бер генә дәреслек кала дигән сүз түгел. Апрельдә федераль исемлеккә кертү өчен яңа дәреслекләр җибәрелде. Алар инде бердәм программага карап эшләнде, – диде Энҗе Гыйзәтуллина.

Ул аңлатып үткәнчә, моңа кадәр үрнәк эш программалары дип йөртелсә, хәзер федераль дип атала. Бу укытучының эшен җиңеләйтәчәк. Ни өчен дигәндә, тели икән, ул шул әзерен генә дә куллана ала. Моңа кадәр туган телләр һәрберсе аерым булып, ФГОС реестр дигән сайтка куелган. Ә хәзер бердәм белем бирү программасына аерым бер бүлек булып кертелгән. Анда туган телләр һәм әдәбиятлардан 130лап программа бар.

Сәрия МИФТАХОВА

Сан

Бүген куллану өчен **100дән** артык дәреслек һәм уку әсбабы бар, яңа программаларга нигезләнеп эшләнгән тагын **26 комплект** Мәгариф министрлыгына җибәрелгән.

***

Узган уку елында Татарстан мәктәпләрендә – **3194**, Россиянең башка төбәкләрендә **1340** татар теле укытучысы белем биргән.

ИРТӘГЕНЕ БҮГЕН УЙЛЫЙСЫ



«Татар-информ»

Гомерең булса, социаль пакеттан баш тартма икән! Алабугада яшәүче Фәния Валиуллина шулай ди. Узган ел бу мөмкинлектән баш тартып, акчалата компенсацияне сайлаган булган ул. Әмма диспансеризация узганда табиблар аңа аяктан егарлык хәбәр җиткерә. Болай да җитди чирдән интеккән Фәния апаның күкрәгендә икенче дәрәҗәдәге яман шеш барлыгы ачыклана.

– Җитди күз авыруыннан интегәм. 2 нче группа инвалидлыгым да бар. Күзгә бик көчле дарулар салам. Шуларны алганда аз булса да ярдәме булыр дип, социаль пакет урынына акчалата компенсацияне сайлаган идем. Узган ел тагын бер җитди чир таптылар. Шунда социаль пакетны сайлыйсы калган икән дип бик нык үкендем. Быел, Алла боерса, бернигә карамый шуны сайлаячакмын, – ди Фәния апа.

Сәламәтлек сагында торган белгечләр дә социаль пакеттан баш тартыр алдыннан жиде кат уйлап, бер кат кисәргә киңәш итә. Отам дип, икеләтә оттыруың ихтимал, дип кисәтә алар.

Билгеле булганча, федераль ташламалардан файдаланучылар (сугыш һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, барлык төркем инвалидлар, Ленинград блокадасы корбаннары) социаль пакет алырга хокуклы. Ул бушлай дарулар белән тәэмин итүне күздә тота. Аннан баш тартучылар исә 1300 сумлык акчалата компенсацияне сайлый ала. Кызганыч, бүген соңгылары күпкә күбрәк, дип күрсәтә белгечләр.

Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Фәридә Яркәева сүзләренә караганда, республикада ташламалардан файдаланучыларның 61 проценты социаль пакеттан баш тарткан. Аларның күбесе Кукмара, Яшел Үзән, Бөгелмә, Баулы, Чүпрәле районнарында яши. Бер ел эчендә Татарстанда социаль пакеттан баш тартучылар саны 1,5 процентка кимегән.

– Кешедә катлаулы һәм дәвалау бик кыйммәткә төшә торган чир табылса, бу аның үзе өчен генә түгел, бөтен гаиләсе өчен зур сынауга әверелә. Социаль пакеттан баш тарткан булса, бигрәк тә. Ник дигәндә, табиб язган даруларның күбесе гадәттә бик кыйммәт була, – ди министр урынбасары.

Шуңа күрә социаль пакет яки акчалата компенсация сайлаганда аеруча игътибарлы булырга киңәш итә белгеч. Бу карарны 1 октябрьгә кадәр кабул итәргә кирәк. Әгәр кеше узган елларда да социаль пакеттан файдаланган булса, быел аңа каядыр барып, яңадан документ тапшырып йөрергә кирәкми. Аның гаризасы автомат рәвештә озайтылачак. Әгәр моңа кадәр ул акчалата компенсация алып, быел социаль пакеттан файдаланырга карар кылган булса, аңа Пенсия фондына мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Яшерен-батырын түгел: чир дигәнең рөхсәт сорап тормый, бүген булмаса, иртәгә китереп «бәрергә» мөмкин. Андый чакта акчалата компенсация алган кеше, кире уйлап, социаль пакет артыннан йөри башларга мөмкин. Әмма 1 октябрьдән соң инде моны эшләү мөмкин булмаячак. Социаль пакетны тагын бер елдан соң гына ала алачак ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Социаль яклау

Түләүләр билгеле

Татарстанда 2024–2026 елларга балалар бакчасы өчен түләү күләме билгеләнде. Татарстан Хөкүмәте карарыннан аңлашылганча, балалар бакчасына түләү хакы баланың яшенә, гаиләдәге балалар санына һәм мәктәпкәчә оешмага йөрү вакытына бәйле.

– Өч яшькә кадәрге бала көненә өч сәгать балалар бакчасында булса, ата-аналар айга – 780 сум (күпбалалы гаилә – 390 сум) түләячәк. Өч яшьтән өлкәнрәк бала өчен түләү – 705 сум (күпбалалы гаилә – 353 сум) тәшкил итәчәк.

– Ясле төркемендәге баланың бакчадагы тугыз сәгате – 2020 сумга (күпбалалы гаиләләргә – 1010 сум) төшәчәк. Өч яшьтән өлкәнрәк балага 1920 (күпбалалы гаилә) 960 сум түләргә кирәк булачак.

Карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керәчәк.

***

Татарстан Хөкүмәте республика вузларында укучы студентлар өчен стипендия күләмен билгеләде. Аның күләме түбәндәгечә булачак:

- көндезге бүлектә специалитет, бакалавриат һәм магистратурада укучылар өчен – 2176 сум;
- аспирант, ординаторларга – 2974 сум;
- урта звено белгечләре әзерләү программасы буенча һөнәри белем бирү оешмаларында укучы студентлар өчен – 792 сум;
- квалификацияле эшчеләр әзерләү программасы буенча көндезге бүлектә укучы студентларга – 567 сум;
- фәнни тикшеренү һәм эшләнмәләр юнәлешендәге вуз аспирантлары өчен – 8062 сум.

Социаль пакеттан баш тартмаска 4 сәбәп

Эдуард НАГУМАНОВ, Республика клиник онкология диспансеры бүлек мөдире:

– Бүген республикада яман шеш диагнозы белән 115 мең чамасы кеше исәптә тора. Соңгы ун елда аларның саны 34 меңгә артты. Кайбер төр яман шеш авыруларын дәвалау елына өч-дүрт миллион сумга төшәргә мөмкин. Еш кына кеше яман шешне җиңдем дип тынычлана да социаль пакеттан баш тарта. Күп тә үтми, онкологка килеп тикшеренгәннән соң мәкерле чирнең кабаттан баш калкытканы ачыклана. Әмма, ничек кенә теләсә дә, бу елны инде ул социаль пакеттан файдалана алмаячак. Ә яман шешне яңадан баш калкыткан чорда (рецидив) дәвалау күпкә кыенрак һәм кыйммәткәрәк төшә. Ник дигәндә, вакыт узган саен яман шеш күзәнәкләренең төзелеше дә үзгәрә. Шул рәвешле моңа кадәр кулланылган дәвалау алымнарының да файдасы тими башлый. Шуңа күрә 1300 сумлык акчалата компенсациягә алданып, социаль пакеттан баш тартканчы, кат-кат уйларга кирәк. Социаль пакет – бик күп кенә авыруларны алдан кисәтеп, шактый акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирүче ярдәм чарасы ул.

Зөлфия КИМ, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш кардиологы:

– Инфаркт, инсульт очракларын кисәтү өчен гел дару эчеп, даими рәвештә табибка күренеп торырга кирәк. Кызганыч, җитди йөрәк-кан тамыры авырулары кичергән кешеләрнең яртысы гына бу киңәшкә колак сала. Шуңа күрә икенче, өченче тапкыр инсульт, инфаркт кичерүчеләр саны арта бара. Аларны дәвалап аякка бастыру да кыенрак. Йөрәк авырулары, гадәттә, үзләре генә түгел, башка җитди чирләр белән янәшә йөри. Шуңа күрә яман шеш, шикәр чиреннән интеккән кешеләрне еш кына безнең бүлеккә кучерергә туры килә. Йөрәк авыруларын дәвалау өчен яңадан-яңа препаратлар чыгып тора һәм алар бик кыйммәт. Социаль пакет урынына сайланган акчалата компенсациягә генә аларны сатып алып булмый.

Гөлнара ВАҺАПОВА, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш эндокринологы:

– Шикәр чире – ачыктан-ачык борчымаса да, нерв системасын какшата торган мәкерле чир. Әлеге авырудан интегүчеләрнең яртысы бөерләр ялкынсынганда, инфаркт вакытында бернинди авырту да сизми. Анда нинди чир барлыгы еш кына табибка баргач кына билгеле була. Шуңа күрә бу урында шикәр чиреннән интегүчеләрнең туганнарына мөрәҗәгать итәсем килә. Әти-әниегез, әби-бабагыз озак яшәсен дисәгез, аларны дарулар белән тәэмин итү ягын кайгыртыгыз. Шикәр чирле кешеләрнең еш кына кан тамырларында да хилафлыклар була. Алар башка җитди чирләргә дә тизрәк бирешүчән. Шуңа күрә шикәр чиреннән интеккән кешеләргә социаль пакеттан баш тарту аеруча куркыныч.

Татьяна КУРЬЯНОВА, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш психиатры:

– Бүген республикада катлаулы хроник психик тайпылышлары булган 36,5 мең кеше исәптә тора. Безнең төп бурыч – ремиссия чорын озайтып, чирнең яңадан кузгалуын булдырмау. Тege яки бу психик чирнең ни рәвешле узуы еш кына даруларга бәйле. Авыру кискенләшкән чорны да җиңелрәк кичерергә ярдәм итә алар. Бу даруларны вакытында, даими рәвештә эчеп торсаң, хастаханәгә ятып дәвалануны булдырмый калырга да мөмкин. Әмма бу дарулар бик кыйммәт тора. Шуңа күрә әлеге очракта социаль пакеттан баш тарту бер дә отышлы түгел.

15 сентябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Фәния ӘХМӘТҖАНОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Агачны кисәрләрме?

Йорт кырыенда карт агачлар үсеп утыра. Шуларны кистерер өчен авыл советына барган идем. Аннан судка җибәрделәр. Андагылар адвокат конторасына озатты. Соңгылары, авыл советыннан язу булмыйча, без берничек тә кисәргә дип әйтә алмыйбыз, диләр. Ул агачларны өч мәртәбә килеп тә карадылар инде. Әмма кисәргә рөхсәт бирүче юк.

Ринат МӨХӘРЛӘМОВ.
Биектау

Биектау районының Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ринат Сабирҗанов:
– Нигә бу проблема белән безгә килмәделәр икән? Юкса, берәр җаен табып, уртак фикергә килгән булыр идек. Әгәр агач зыянлы, кеше гомеренә куркыныч китерә икән, без аны шундук кистертәбез. Урынга барып карап, мәсьәләне хәл итәрбез.

Канауны ябарлармы?

Йортыбызны сатып алганда, кыш көне иде. Бакчабыз уртасыннан пычрак су агучы канау бардыр дип уйламадык та. Язга чыккач, бар да күренде. Инде нигә еллар бөтен пычрак кар су безнең бакча аша агып ята. Шул канауны күмеп булмасмы дигән идек. Район хакимияте башлыгына да кердем. Ул урынбасарларына бу эшне башкарырга кушкан иде. Әмма әле дә канау ачык.

Алия МОРТАЗИНА.
Мамадыш

Мамадыш шәһәренең Башкарма комитет җитәкчесе Рәшит Гарипов:
– Әлеге канау Советлар Союзы чорында төзелгән инде ул. Аны күмәргә кирәген беләбез. Җәй көне башка эшләр булды, өлгермәдек. Шушы араларда канау күмеләчәк.

«Хезмәт ветераны» тиешме?

Китапханәдә эшлим. Гомуми стажым – 41 ел. Бөтенроссия авыл хуҗалыгы җанисәбе вакытында миңа медаль биргәннәр иде. Шуның таныклыгын таба алмыйм. Аны ничек кире ясатырга икән? Тагын бер соравым бар: ул медаль миңа «Хезмәт ветераны» исемен алырга мөмкинлек бирәме?

Сания СӘЛИМУЛЛИНА.
Югары Ослан районы

«ВТ» юристы Булат Закиров:
– Таныклыкны югалткач, сезгә аны биргән оешмага барырга кирәк. Анда мәгълүмат кала. Медаль белән тапшырылган таныклыкны яңадан алып булачак. Бу медаль дәүләт статистикасы хезмәтендә штатта эшләгән, Росстатның территориаль органнарында, хезмәт килешүе төзеп эшләгән кешеләргә «Хезмәт ветераны» исемен алырга хокук бирә. Ә инде 2010 елда узган җанисәп вакытында катнашкан, әмма дәүләт статистика хезмәтендә эшләмәгән кешеләргә бирелми. Тулырак мәгълүмат алыр өчен, үзегез яшәгән районның социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кайтара аламмы?

Кибеттә ялгыш кына коньяк шешәсен төшереп ваттым. Кибетче шуны миннән түләтте. Ул дөрес эшләгәнме?

Алсу. Чаллы

«ВТ» юристы Булат Закиров:
– Әгәр сез юеш идәндә таеп китеп, эчемлекләр торган стеллажга бәрелеп товарга зыян китергәнсез икән, монда идән юучы, җыештыручы җавап бирә. Кибеттә рәт аралары тар булып, арба белән узганда ватылган икән, бу очракта шикаять белән кибет хуҗасына мөрәҗәгать итәргә була. Сезнең гаеп белән ватылмаганны дәлилли аласыз икән, түләнгән акчаны кире кайтара аласыз. Барысын да камералар аша карарга була.

Кайчан алмаштырачаклар?

Без Балык Бистәсендәге Октябрьнең 60 еллыгы урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан күпфатирлы йортта яшибез. 14 ай элек безнең йортта 7 счетчик ватылды. Районнан белгечләр килеп алыштырды. Әмма алар озак эшләмәде, бер ай дигәндә кабат ватылдылар. Казаннан «Татэнергосбыт» белгечләре кайтып алмаштырачак, көтегез, диделәр. Җиде ай узды инде, әле һаман килүче юк. Ул счетчиклар эшләмәгәч, без гомуми йорт чыгымнарын да күбрәк түлибез булып чыга бит инде. Аларны кайчан алмаштырырга җыеналар икән?

Раилә ДУДКО.
Балык Бистәсе

«Татэнергосбыт» идарәсеннән:
– 2018 елның 27 декабрендәге 522 номерлы федераль закон нигезендә «Татэнергосбыт» идарәсе белгечләре 2020 елның 1 сентябреннән Татарстандагы күпфатирлы торак йортларда урнашкан сафтан чыккан, яраклылык вакыты беткән электр энергиясе счетчикларын алмаштыра башлады. Балык Бистәсендәге Октябрьнең 60 еллыгы урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан күпфатирлы йортта 80 счетчикның 14е алмаштырылды. Идарә белгечләре тарафыннан уздырылган тикшерү барышында хәзерге вакытта биредә нибары 1 счетчикның гына ватык булуы ачыкланды. Якын арада ул алмаштырылырга тиеш.

Башкалары эшләрме?

Казан шәһәрендә 25кә якын радиостанция эшли дип беләм. Ә минем безнең Кайбыч районында бары тик ике радио каналы гына «тота». Берсе – «Болгар», икенчесе – «Радио России». Калган радио каналларын да тыңлыйсыбыз килә. «Тәртип», «Күңел», «Китап», «Миллениум»нар да эшләсен иде ул бездә. Шуны хәл итеп булмасмы?

Сәгадәт ӘКРӘМОВ.
Кайбыч районы

«Татмедиа» АҖ җитәкчесенең радио каналлары белән эшләү юнәлеше буенча урынбасары Алмаз Миргаязов:
– Һәр радио каналын мобиль кушымта аша тыңлап була. Телефонга йөкләтәсең дә, нинди радио каналы кирәк, шуны тыңлыйсың. Заманча технологияләр аша әллә ниләр эшләп була хәзер. Эфир дулкыны зур чыгымнар таләп итә. Милләтебезнең йөзен, телебезне сакларга бик теләсәк тә, без радио каналларын авылларда да тыңларлык итеп эшли алмыйбыз. Бу, беренчедән, физик яктан да башкарып чыга торган эш түгел, финанс ягыннан да моны хәл итеп булмаячак.

Пенсиям дөрес исәпләнгәнме?

2004 елда 1981–1985 еллардагы хезмәт хакым турында белешмә алып, пенсия бүлегенә илттем. 44 ел стажым бар. Хәзерге алган акчам белән килешмим. Миңа пенсияне дөрес исәпләгәннәрме? Шуны белешсәгез иде.

Әгълиулла ГАЛӘВИЕВ.
Әтнә районы

Россия Социаль фондының Татарстан бүлеге матбугат үзәге:
– Пенсионерларның пенсия күләмен газета аша әйтә алмыйбыз. Бу – шәхси мәгълүмат. Аның 80 яшьтән соң түләнелә торган акчасы ике мәртәбә артуын, әле тагын караучысы өчен 1200 сум түләнгәнен генә әйтә алабыз. Шуңа күрә Әгълиулла абыйга үзе яшәгән районның клиентлар белән эшләү хезмәтеннән безнең фондка менә бу адреска (http://pension.sprrt.ru/.) интернет аша хат җибәрүен сорыйбыз.

Нигә акчам кимеде?

Ике ай пенсиям дүртәр мең сумга кимеп килде. Хикмәт нидә икәнен һич аңламыйм. Киресенчә, акча арта, дигәннәр иде. Нигә кими икән?

Рәсим ЯББАРОВ.
Ютазы районы Бәйрәкә авылы

Россия Социаль фондының Татарстан бүлеге матбугат үзәге:
– Рәсим Яббаровның пенсиясе 2022 елның декабрендә кимегән. Авыл җирендә эшләүчеләр өчен өстәмә бирелә торган акчаны түләми башлаганнар. Чөнки әлеге кеше ноябрь – февраль айларында эшләгән. Мартта эштән туктагач, әлеге түләүне яңадан кайтарганнар. Исегезгә төшерәбез: пенсиягә өстәмә акча элек авыл җирендә эшләгән, әмма әлеге вакытта эшләмәүче пенсионерларга түләнә.

Штраф сугарлармы?

Ел узып бара. Мин әле дә салым түләү өчен белдерү кәгазе алмадым. Штраф сугарлармы икән?

Кадрия ХАЛИКОВА.
Казан

Казан шәһәренең 6 нчы салым инспекциясенең баш белгече Рәмзия Мөхетдинова:
– Салым суммасы 100 сумнан ким яки түлисегез юк икән, бу очракта почта аша хат җибәрелми. Тагын шунысы бар: салым түлисе сумма 100 сумнан ким икән, киләсе елда гына хәбәр килергә мөмкин. Түләү квитанциясе «салым түләүченең шәхси кабинеты»ннан файдаланучыларга электрон рәвештә җибәрелә. Әгәр «шәхси кабинеты»гыз булмаса, түләү кәгазен теләсә кайсы салым инспекциясеннән алырга мөмкин.

Кемнәрнеке генә арта икән?

80 яшь тулгач, пенсиягә 15 мең сум акча өстәлә, дигәннәр иде. Бабаемныкы артып килде, минеке – юк. Нигә шулай соң ул?

Нурҗиһан САДЫЙКОВА.
Казан

Россия Социаль фондының Татарстан бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин:
– 80 яшь тулгач, пенсиянең фиксацияләнгән өлеше генә ике мәртәбә арта. 2023 елның 1 гыйнварыннан бу фиксацияләнгән түләү күләме – 7567 сум 33 тиен. Димәк, иминият акчасын алучы кешенең пенсиясенә 15 мең 134 сум 66 тиен акча өстәләчәк. Аның өчен гариза язасы юк. Ул үзе автомат рәвештә күчә. Инвалидлык яки социаль пенсия алучыларның акчасы, 80 яшь тулса да, артмый.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

11 сентябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «БИЧАРАКАЙ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «МОЯ ЧУЖАЯ ДОЧКА». Телесериал (с субтитрами) 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16 +
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». Телесериал 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00, 00.50 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
00.00 «Соотечественники». Владимир Вавилов. Дом милосердия 16+
00.25 «Каравай» 6+
01.15 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Ринат Закиров турында телеочерк 16+
15.30, 03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Адымнар» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Калеб» 6+
21.55 «Туган авылым» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Ватандашлар» 16+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.30 «Мәңгелек... Ирек... Хисләр...» Ирек Бaһманов турында телеочерк 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Премьера. «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
02.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
02.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Карина Андоленко, Роман Маякин, Александр Голубев, Лариса Удовиченко, Михаил Жигалов. «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анна Ковальчук «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.45 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.15 «Игра миллионов» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.45, 14.45 Новости
07.05, 15.20, 21.00, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.25, 03.05 Специальный репортаж 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Футбол. Чемпионат Европы-2024. Отборочный турнир. Обзор 6+
12.50 «Есть тема!» Прямой эфир
14.50 «География спорта. Красноярск» 12+
15.55 Футбол. Товарищеский матч. Молодёжные сборные. Узбекистан – Россия. Прямая трансляция из Узбекистана.
18.00 «Громко» Прямой эфир
18.50 Футбол. Чемпионат Европы-2024. Отборочный турнир. Армения – Хорватия. Прямая трансляция
21.35 Футбол. Чемпионат Европы-2024. Отборочный турнир. Исландия – Босния и Герцеговина. Прямая трансляция
00.50 Лёгкая атлетика. Мировой континентальный тур. Трансляция из Хорватии 0+
03.00 Новости 0+
03.25 Стрельба из лука. Кубок мира. Финал. Блочный лук. Трансляция из Мексики 0+
04.50 Академическая гребля. Чемпионат мира. Трансляция из Сербии 0+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ» (S) 16+
22.15, 00.00 Детектив «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
00.55 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.25 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40 «Понять. Простить» 16+
11.45 «Порча». «Скрепка». «Магнитка» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «КУКУШКИ» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.30 «Порча» 16+
01.25 «Знахарка» 16+
01.50 «Верну любимого» 16+
02.20 «Голоса ушедших душ» 16+
02.45 «Тест на отцовство» 16+
04.25 «Давай разведёмся!» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «1812». Докудрама. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 23.45 «МАКСИМ ПЕРЕПЕЛИЦА» 12+
13.25, 15.05, 17.15 «ЗНАХАРЬ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Крылья СССР. Год за годом». Документальный сериал. «1961 год». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам». Премьера! 16+
20.10 «Загадки века с Сергеем Медведевым». «Альфред Розенберг. Путь к виселице» 12+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «Двенадцать кремлей России». Документальный сериал. Премьера! 12+
01.35 «АТАКА» 12+
03.05 «Хроника Победы». Документальный сериал 16+
03.30 «ЗНАХАРЬ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

12 сентябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «БИЧАРАКАЙ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «МОЯ ЧУЖАЯ ДОЧКА». Телесериал 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». Телесериал 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Динамо» (Мн). Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Красота русского пейзажа 6+
00.50 «Соотечественники». Алтер Литвин. Реабилитированный дважды 16+
01.15 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.40 «Таяну ноктасы» 16+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.30 «Баяның кулыңнан төшмәде». Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Премьера. «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.15 Футбол. Сборная России – сборная Катара. Прямой эфир (S)
20.05 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 «УГРЮМ-РЕКА» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 К 90-летию Татьяны Дорониной. «НЕ ЛЮБЛЮ КИНО» 12+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
03.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
04.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Карина Андоленко, Роман Маякин, Александр Голубев, Лариса Удовиченко. «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анна Ковальчук в детективном телесериале «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.45 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.15 «Игра миллионов» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.00, 12.45, 14.45 Новости
07.05, 15.20, 18.15, 20.35, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.25, 03.05 Специальный репортаж 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Футбол. Чемпионат Европы-2024. Отборочный турнир. Обзор 6+
12.50 «Есть тема!» Прямой эфир
14.50 «Что по спорту? Уфа» 12+
15.55 Хоккей. OLIMPBET Чемпионат МХЛ. МХК «Динамо» (Москва) – «Тайфун» (Приморский край). Прямая трансляция
18.55 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «СКА Минск» (Белоруссия) – «Виктор» (Россия). Прямая трансляция
21.35 Футбол. Чемпионат Европы-2024. Отборочный турнир. Норвегия – Грузия. Прямая трансляция
00.50 Футбол. Чемпионат мира-2026. Отборочный турнир. Венесуэла – Парагвай. Прямая трансляция
03.00 Новости 0+
03.25 Стрельба из лука. Кубок мира. Финал. Классический лук. Трансляция из Мексики 0+
04.50 Футбол. Чемпионат мира-2026. Отборочный турнир. Перу – Бразилия. Прямая трансляция

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ» (S) 16+
22.15, 00.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
00.45 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+
04.35 «Военно-исторические маршруты» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.25 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40 «Понять. Простить» 16+
11.45 «Порча». «Под замком». «Прилипала» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ПО ВОЛЕ СЛУЧАЯ» 16+
23.15 «Понять. Простить» 16+
00.20 «Порча» 16+
01.15 «Знахарка» 16+
01.40 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «Тест на отцовство» 16+
04.15 «Давай разведёмся!» 16+
05.05 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «ЗНАХАРЬ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 23.45 «ВОЗВРАЩЕНИЕ «СВЯТОГО ЛУКИ» 12+
13.25, 15.05, 17.15 «ЗНАХАРЬ». Телесериал. 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Крылья СССР. Год за годом». Документальный сериал. «1962 год». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого». «Поджог Рейхстага и «огонь» майдана. Поиск точки возгорания» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «Двенадцать кремлей России». Документальный сериал 12+
01.35 «КРИМИНАЛЬНЫЙ ОТДЕЛ» 16+
03.00 «ЗНАХАРЬ». Телесериал. 5-я и 6-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләүләре өчен Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары **Анфимова** Алла Леонидовна, Татарстан Республикасы Рәисенең матбугат хезмәте җитәкчесе **Галимова** Лилия Камил кызы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнделәр.

* * *

Җәмәгать тукланув системасын үстерүгә һәм халыкка югары культуралы хезмәт күрсәтүне тәэмин итүгә мөһим өлеш кертүе, актив иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге өчен «Эдем» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Алексеевск районы) **Сафина** Гөлнур Таһир кызы «**Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Һөнәри эшчәнлектә югары казанышларга ирешүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) Ярдәмче оешмалар мәгълүмат технологияләре идарәсе директоры **Дубков** Максим Александрович Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен **Гафуров** Иван Мөбарәк улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлегенең «Россия кооперация университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган мәгариф оешмасының Казан кооперация институты (филиалы) Татар мәдәни үзәге җитәкчесе **Абдуллина** Флюра Галимҗан кызына, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенең рәссам-фотографы **Гарифуллин** Фаат Абдрахман улына, рәссам, «Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге» төбәк иҗат иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Шәймәрданов** Альфрид Мулләхмәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Әхмәтҗанов** Руслан Илгиз улына, «Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Зиннәтова** Диләрә Фәргать кызына, «Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Яруллина** Энҗе Мөдәррис кызына, «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле артисты – солисты-инструменталисты **Мәүлетов** Роберт Кирам улына, «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле вокалчы артисты (солисты) **Шәяхмәтов** Радик Раил улына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Казан шәһәренең «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе хезмәткәрләре: 1 номерлы троллейбус депосы баш инженеры **Аполлонов** Дмитрий Павловичка, 1 номерлы троллейбус депосы троллейбус йөртүчесе **Гарипов** Наил Камалетдин улына, 2 номерлы троллейбус депосы троллейбус йөртүчесе **Гыйззәтуллин** Равил Кашаф улына, 2 номерлы троллейбус депосы троллейбус йөртүчесе **Дубровин** Валентин Геннадьевичка, 2 номерлы троллейбус депосы диспетчеры **Савагина** Эльмира Николаевнага, 1 номерлы троллейбус депосы троллейбус йөртүчесе **Сибгатуллин** Марат Хәким улына, электр депосы компрессор җайланмасы машинисты **Федоров** Иван Григорьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«ТаграС-ТрансСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары **Арслангираев** Шапи Багатир улына, «Апас-Мол» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте административ-идарә персоналы икътисад һәм финанслар буенча директор урынбасары **Гыйбадуллина** Зөлфия Сабир кызына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының икътисад бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Зарипова** Ләйсән Равил кызына, «ЭНИКС» акционер җәмгыятенең икътисад һәм финанс мәсьәләләре буенча баш белгече **Побежимова** Энҗе Мигран кызына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТУК ЯТАСЫ ТҮГЕЛ

Кеше гомеренең өчтән бер өлешен йоклап уздыра, ди галимнәр. Йокы бик күп төрле авыруларны булдырмый кала, иммунитетны ныгыта. Шуңа күрә күзгә аяк басканда, бигрәк тә укулар башланган чорда моңа аеруча зур игътибар бирергә кирәк, ди белгечләр. Татлы йокы сере нидә?

shutterstock.com

КФУ клиникасының табиб-сомнологы Лилия ШАҺИӘХМӘТОВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Йокы туймау нәрсәсе белән куркыныч?
– Йоклаганда организмның бөтен функцияләре торгызыла, мускулларыбыз көч туплый, баш мие исә көн дәвамында җыйган кирәкле мәгълүмат-белемнәрне ныгыта, кирәкмәгәненнән арына. Йоклаганда организмның яшәеше өчен кирәкле гормоннар да бүленеп чыга. Кешенең йокысы туймаса, бу процесслар булмыйча кала диган сүз. Шул рәвешле кешенең иммун системасы какшый, ялкынсынуга бәйле авырулар көчәя. Хәлсезлектән интегә, аягүрә йоклап йөри, баш авыртудан, хәтерсезлектән зарлана башлый. Тәүлек дәвамында тиешенчә йокламаган кеше йөрәк-кан тамыры, яман шеш авыруларына да тизрәк бирешә.

:: Чамадан тыш озак йокларга яратучыларга ни диярсез?
– Артык озак йоклау да зыянлы, билгеле. Әмма монда иң элек кешенең ни сәбәпле шулай озак йоклавын ачыкларга кирәк. Әгәр кеше алдагы көндә тәүлек буе йокламыйча, хәзер шул рәвешле йокысын туйдыра икән, монда шикләнергә җирлек юк. Әмма саусәламәт кеше тик торганда кирәгеннән артык йоклый алмый. Йоклаганда бер мизгелгә сулышы тукталып алудан (апноэ) интеккән кешеләр еш кына озак йоклый. Бу аңлашыла да. Сулыш туктап торган саен баш мие уянырга мәҗбүр була. Шул рәвешле кеше хәтта 12 сәгать йокласа да, йокысы туймаячак. Рульдә йокыга китү очраклары да нәкъ менә апноэдан интегүчеләр арасында күбрәк очрый.

:: Нинди билгеләр күзәтелгәндә кичекмәстән сомнологка мөрәҗәгать итәргә кирәк?
– Әгәр кеше өч ай дәвамында йокысызлыктан тилмерсә, бер уянгач йокыга китә алмыйча ятса һәм бу күренешләр атнага бер-ике мәртәбә кабатланса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Озаккарак сузылган саен, йокыга бәйле проблемаларны хәл итү дә кыенрак.

:: Ни өчен кеше көненә кимендә 8 сәгать йокларга тиеш?
– Сигез сәгать – уртача алынган сан ул. Чынлыкта, һәр кеше индивидуаль булган кебек, аңа кирәкле йокы вакыты да аерыла. Берәүнең 4–5 сәгать йоклап та йокысы туяра, икенче берәүгә моның өчен 10–12 сәгать кирәк булырга мөмкин. Икесе дә норма санала. Иң мөһиме – кеше йоклап торгач үзен яхшы хис итәргә тиеш.

:: Бер вакытта йокларга ятып, бер вакытта уянырга да кирәк, диләр...
– Безнең организм сәгать кебек эшли. Менә шул төгәллек югалмасын өчен, дөрестән дә, бер вакытта йокларга ятып, бер вакытта уянырга кирәк. Билгеле бер төр гормоннар – төнлә, икенче берләре – иртән, тагын бер ише көндез бүленеп чыга. Моның өчен организмның биологик сәгатьләре дөрес эшләргә тиеш. Кешенең сәгать ничәдә йокларга ятуыннан бигрәк, аның моны ни дәрәҗәдә даими эшләве мөһимрәк. Әйтик, кеше иртәнге өчтә дә йокларга ятарга мөмкин. Әмма организмга зыяны килмәсен, ул шушы гормоннар бүленеешен җайлап бетерсен өчен, кеше көн саен иртәнге өчтә ятарга тиеш.

ЙОКЫСЫЗЛЫКНЫ БУЛДЫРМАУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

✓Көндәлек тормышыбызда стресслардан котылып булмый. Әмма без аларны дөрес итеп кабул итәргә өйрәнә алабыз. Моңа төшенгән кешене йокысызлык кебек афәт борчымаячак.

✓Йокысызлыктан интеккән кешеләргә начар хәбәрләрне дә сирәк тыңларга кирәк. Йөрәккә якын алмыйм дисәң дә, алар барыбер баш миендә туплана бара. Алар үз чиратында йокыга йогынты ясый.

✓Йокларга 1–1,5 сәгать кала телефон, гаджетларны сүндереп, читкә алып куярга кирәк.

✓Йоклар алдыннан китап укырга ярый. Ләкин ул ярсыта, елата, борчуга сала торган әсәр булмаска тиеш.

:: Йокы татлы булсын өчен ничек тукланырга кирәк?
– Йоклар алдыннан авыр эшкәртелә торган ризыклар ашарга ярамый. Организм моның өчен бик күп көч сарыф итә. Аларның эшчәнлеген исә баш мие контрольдә тота. Организмда мондый зур эшләр кайнаганда ничек йокыга китеп булсын ди! Йоклаган очракта да, ул сыйфатлы булмаячак. Шуңа күрә соңгы тапкыр йокларга 3–4 сәгать кала ашарга кирәк.

:: Каһвә, чәйне кайчан эчү хәерлерәк?
– Каһвә составындагы кофеин берәүләрне уятып җибәрергә, икенчеләрендә исә аны эчкәннән соң бернинди үзгәреш тә күзәтелмәскә мөмкин. Шуңа күрә каһвәгә бәйлелеге көчле булган кешеләргә йокларга алты-сигез сәгать кала бу эчемлекне кулланмаска киңәш итәр идем. Йоклар алдыннан чәй эчәргә, шоколад ашарга да киңәш ителми.

:: Баласы мәктәптә укыган ата-ана нинди кагыйдәләрне истә тотарга тиеш?
– Иң беренче чиратта укучының йокы режимы көйләнгән булырга, ул бер вакытта йокларга ятып, бер вакытта торырга тиеш. Бала организмы йоклаганда ял итеп кенә калмый, үсә дә. Мәктәптә алган белемнәр истә калсын өчен дә укучы бала вакытында ятып, йокысы туйганчы йокларга тиеш.

:: Көндез черем итеп алгач, еш кына баш авырта, бөтен гәүдә сызлый. Көндез йоклау зыянлы диган сүзме бу?
– Төнлә тиешенчә йоклаган кешегә көндезге йокы файдага гына. Әмма ул көндезгә сәгать өчкә кадәр булырга һәм ярты сәгать-кырык минуттан да артмаска тиеш. Кеше төнлә начар йоклый, йокысызлыктан интегә, йә булмаса, уяна-уяна йоклый икән, көндез черем итеп алгач, аның төнге йокысы тагын да начарланачак. Шуңа күрә аларга көндез йокларга киңәш ителми.

Саклап куй!

Бер фасылдан икенчесенә күчкәндә бит тиресе аеруча тәрбиягә мохтаҗ. Әлеге табигый битлекләрнең файдасы тими калмас.

Табигый пилинг. Иртә-кич биткә кыяр, помидор яки җиләк сөртсәң, кибеттә сатылган косметик чаралар бер читтә торсын! Дөрес, нәтиҗәсе булсын өчен кешенең бу җимешләргә аллергиясе булмаска тиеш.

Бит тиресен агартучы битлек. 1 помидорга 1 аш кашыгы крахмал, 1 аш кашыгы зәйтүн мае салып, биткә сөртергә кирәк. Помидор тән тиресен агартып кына калмыйча, аны бик яхшы тукландыра, дымландыра да. Бу битлек бит тиресе майлы булган кешеләргә аеруча файдалы булачак.

Алмадан битлек. Алмадан сок ясаганда, йә булмаса, парда пешергәннән соң, гадәттә, аның йомшак өлеше кала. Аны ташларга ашыкмагыз. Бер алма йомшагына бер аш кашыгы зәйтүе мае, 1 аш кашыгы сөт яки кефир өстәп, биткә сөртергә мөмкин. Бу битлек тирене бик яхшы дымландыра, кояшта кызынганнан соң хәлсезләнгән күзәнәкләргә көч өсти.

Сливалы битлек. Сливадан да шундый ук битлек ясап була. Слива йомшагына 1 аш кашыгы зәйтүн мае, 1 аш кашыгы крахмал кушып, бит тиресенә сөртсәң дә файдалы.

Кишерле битлек. Тән тиресе кызынган төс алсын дисәгез, ике дә уйламый шушы битлекне ясый аласыз. Уылган кишергә 1 аш кашыгы зәйтүн мае, 1 аш кашыгы солы ярмасы, 1 йомырка сарысы кушып, яхшылап болгатырга кирәк. Мондый битлек тән тиресенең төсен яхшырта, ялтырата. Ак тәнле кешеләр бераз каралып киткәндәй була.

P.S. Алда телгә алынган битлекләрне һәркем үз тән тиресенә туры китереп үзгәртә ала. Тән тиресе коры булган кешеләр майлы каймак, кефир да кушып җибәрсен. Бит тиресе, киресенчә, майлы булган кешеләр исә йомырка агы, крахмал, бал өсти ала.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина
СЕМЕНОВА

Белсәң, зыян итмәс

МАЙОНЕЗМЫ, ӘЛЛӘ КАЙМАКМЫ?

Салат ясау, соус әзерләү өчен иң еш кулланыла торган ризыклар бу. Ләкин әледән-әле, тегесе дә, монысы да зарарлы, чөнки составында май күп, дигән фикерне ишетергә туры килә. Ләкин организмга май да кирәк бит. Көндәлек ашау-эчүдә аның өлеше 30 процент булырга тиеш, ди белгечләр. Шул ук вакытта бер кашык үсемлек мае (бик «белдекле» кешеләр майонез яки каймакны шуңа алыштырырга киңәш итә) 100 процент майдан тора!

Каймак майонезга караганда майлырак, шуңа күрә тегесенә өстенлек бирергә кирәк, диючеләр дә бар. Чынында исә каймакның диетик сортларында май күләме хәтта майсыз майонезныкыннан (нигезен үсемлек майлары тәшкил итә чөнки) да кимрәк. Инде килеп, каймактагы май майонездагыныкыннан зарарлы, чөнки сыер маенда холестерин күп, дип акыл өйрәтүчеләр дә байтак. Әмма, белгечләр ышандырып әйткәнчә, табигый каймактагы холестеринның әллә ни зыяны юк. Майонездагы «трансжир»лар, төрле Е-өстәмәләр исә күпкә куркыныч.

Әлбәттә, ризык әзерләгәндә нәрсәне кулланасын һәркем үзе хәл итә. Шулай да белгечләр майлылыгы зур булмаган табигый каймакка өстенлек бирергә киңәш итә. Анда май микъдары аз, ә аксым күп.

ОРЛЫКЛАР ӘЗЕРЛИБЕЗ

Кайбер бакчачылар, кибеттәгеләренең еш кына сыйфатсыз булып чыгуы сәбәпле, яшелчә орлыкларын үзләре әзерли. Әлбәттә, гибрид сортларга кагылмый бу. Моның өчен бик кулай вакыт җиткәнен исәпкә алып, агроном Татьяна Мирончик киңәшләрен тәкъдим итәбез.

Помидор

Орлыкка калдыру өчен төп сабакта үскәнен һәм беренчеләрдән булып өлгергәнен сайлап алабыз. Бик нык пешеп, йомшарган помидорны урталай кисәбез. Орлыкларын чәй кашыгы белән алабыз. Әчетеп, орлыкларны тышчасыннан аерабыз. Моның өчен аларны пыяла яки пластик савытка салып, үз согында 3–4 көн тотабыз (бүлмә температурасы +25 градус чамасы булса әйбәт). Орлыклар тышчасыннан тизрәк аерылсын өчен савытны әледән-әле селкеткәләп торабыз. Әчү процессы төгәлләнгәч, өскә калкып чыккан зәгыйфьрәкләрен түгәбез, ә төпкә утырып калганнарын краннан агып торган суда юабыз. Ләкин су җылымса гына булырга тиеш. Кайнаррак булса, юганнан соң кайбер сорт орлыклар бүртә башларга мөмкин.

Татлы борыч

Орлыкка дигәнен (аскы ботактагысын калдыру әйбәтрәк, чөнки тизрәк өлгерә) тулысынча өлгереп җиткәнче куагыннан өзмибез. Өзгәч, бүлмәдә 1–2 көн тотабыз. Шуннан, үзәгенә тимичә генә, борычның өске өлешен кисеп алабыз. Кипшерсен өчен коры урынга куябыз. Үзәгендә урнашкан орлыкларга (борычның әчке өлешендәге – бүлгеләрендәгеләргә орлыкка калдыру өчен ярамый) гына игътибар итәбез. 2–3 көн узганнан соң, орлыклар аз гына тиюгә үк коела башлагач, бер-ике көн кояшлы урында тотабыз. Кояш нурлары тәэсирендә алар тизрәк кибә, берочтан авырулары да юкка чыга. Мондый орлыклар күләгәдә киптерелгәннәреннән озаграк шытып чыгарга мөмкин. Ләкин сыйфаты яхшырак булачак.

Әгәр борыч түтәлдә өлгереп җитмәсә (сортына карап, кызара яки сарылана гына башласа), аны тәрәзә төбендә өлгертеп җиткерүдән мәгънә юк. Бу очракта орлыкларын алып киптерергә, шуннан 3–5 көн буе +45...+50 градуслы температурада тотарга кирәк. Болай эшләгәндә, орлыклар сыйфатлы булачак.

Баклажан

Орлыклык баклажанны, көннәр аяз торса, ничек тә озаграк куагында тотарга тырышабыз. Шуннан соң әле тагын 2–3 ай буе бүлмәдә өлгертеп җиткерү таләп ителәчәк. Өлгереп җитмәгәненең орлыклары начар тишеләчәк.

Баклажан, тулысынча йомшарып, зәңгәрсу-коңгырт төскә кергәч, урталай ярабыз да орлыкларын алып киптерергә куябыз. Орлыкларны юарга кирәкми.

Шул рәвешле кабак, ташкабак, гомумән, теләсә кайсы яшелчә орлыгын үзебез әзерли алабыз.

Кирәге чыгар

Фольга серләре

➤Көмеш кашыкларны ялтырату өчен кулланырга мөмкин. Савытның төбенә фольга җәябез (ялтыравыклы ягы өстә калырга тиеш). Кашык-чәнечкеләрне шунда урнаштырабыз. Стаканның дүрттән бер өлеше күләмендә содага, стакан тулганчы, җылы су агызабыз да, болгатып, савытка салабыз. 15 минуттан соң кашыклар, кибеттән алгандагы кебек, ялтырап калачак.

➤Фольга белән кайчы үткенләргә дә була. Моның өчен фольга кисәген кискәләргә генә кирәк. Кайчы үткенләнәчәк, шул ук вакытта тутыгы да юкка чыгачак.

➤Фольга җылылык кайтару үзенчәлегенә ия. Кер үтүкли торган тактаның тышлыгы астына шуны җәйгән очракта, кием бик җиңел һәм тиз үтүкләнәчәк.

Аш-су

Чөгендерле кәтлит

Римма ЖАМАЛИЕВА рецепты

Чөгендер кәтлиткә татлырак тәм биреп, ризыкны тагын да йомшаграк, сусыл һәм тәмлерәккә әйләндерә.

Кирәк булачак: 400 г сыер ите фаршы, уртача зурлыктагы 1 чөгендер, 1 баш суган, 1–2 теш сарымсак, 1 чеметем кипкән һәм вакланган яшел тәмләткеч, 1 аш кашыгы геркулес, берничә аш кашыгы зәйтүн мае, тәменчә тоз, төелгән кара борыч.

Суганны ваклап турыйбыз. Таба төбенә май салып, суганны 2–3 минут кыздырып алабыз. Чөгендерне вак тишекле угыч аша чыгарабыз.

Фаршка кыздырылган суган, чөгендер, сарымсак (ваклап туралган), геркулес (кәтлит таралып китмәсен өчен), кипкән тәмләткечләр, тоз, борыч өстибез. Барысын бергә болгатабыз. Фарш корырак кебек булса, аз гына май тамызабыз. Кәтлитләр әвәләп, табада ике ягын да 2–3әр минут кыздырып алабыз. Шуннан, капкач белән каплап, салмак кына утта тагын 3–4 минут тотабыз.

Теләсә кайсы гарнир белән (минем үземә пешкән яшелчә гарниры ошый) табынга куябыз.

Киңәш

КӘБЕСТӘ ХИКМӘТЛӘРЕ

•Кыздырылган кәбестә коры һәм тәмсез була. Аны башта 5 минут пешереп алганнан соң гына кыздырырга кирәк.

•Пешергәндә, кәбестәдән тәмсез ис чыга. Истән котылу өчен суына кабыгы-ние белән берничә әстерхан чикләвеген юып салырга кирәк.

•Суына бер чәй кашыгы лимон согы өстәп җибәрсәң, кәбестә төсен үзгәртмичә, ап-ак булып пешәчәк.

•Бәлеш эчлеге ясау өчен кәбестәне турагач, иң элек кайнар су белән пешекләп алыгыз. Шуннан соң бер минут салкын суга салып тотыгыз. Суын сыгып, табада кыздырыгыз. Болай эшләгәндә, кәбестәнең төсе үзгәрмәячәк – коңгырт төскә кермәячәк һәм бик тәмле булачак.

НӘСЕЛДӘН БАШЛАНА

«Ата – улны, ана кызны белми». Әлеге гыйбарәне бүгенге заманга бәя биргәндә кулланырга яратабыз. Туган туганын белми яшәү дә гадәти күренешкә әйләнеп бара хәзер. Ә бит туганлык җепләре, нәсел җебе, нәсел көче элек-электән иң зур кыйммәтләрнең берсе санала. Нәселне ничек сакларга? Ни өчен без җиде буын әби-бабайларыбызны белергә тиеш?

Әлеге сораулар белән «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИНга мөрәҗәгать иттек.

:: Динебез нәсел көче, туганлык җепләренә нинди мөнәсәбәттә?

– Рәсүлебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм ачыктан-ачык: «Әгәр дә кем хәерле һәм озын гомер теләсә, туганлык җепләрен өзмәсен», – ди. Шул рәвешле без хәерле, озын гомердә яшәвебезне телибез икән, ул вакытта туганлык җепләрен өзмәскә кирәк. Кызганыч, бүген еш кына моның киресе күзәтелә. Соңгы арада тормышыбызда кайгы-хәсрәт артты. Бүген зиратларда күпме яшьләр ята... Моңа, бәлки, күпмедер дәрәҗәдә туганлык җепләрен өзүебез, аның кадерен белмәвебез дә сәбәпчедер.

:: Нәселгә карап ир яки хатын сайлау ни өчен мөһим?

– Бу күренеш пәйгамбәрләр заманында да булган. Рәсүлебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ир-ат, хатын сайлаганда, матурлыкка, байлыгына, нәселенә карарга мөмкин. Ләкин иң мөһиме – ул дингә, ихласлыкка, тәкъвалыкка карасын», – ди. Бу, иң беренче чиратта, балаларың иманлы, бәхетле-тәүфыйклы, нәселең дәвамлы, нык булсын өчен кирәк.

:: Нәселдә кызлар гына туу нәсел бетүне аңлатамы?

– Әлбәттә, юк. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм киресенчә: «Әгәр дә кем өч кыз үстерсә, аларга тәрбия бирсә, алар иманлы, ихлас, намазлы, уразалы булсалар, бу эти белән әни җәннәткә керер», – диде. Шуңа күрә кыз үстерү ул – бик саваплы, изге эш. Нәсел дә киселми. Шәҗәрә төзегәндә, без бит эти ягын да, әни ягын да барлыйбыз. Туганнар һәм нәсел ул эти ягыннан да, әни ягыннан да була.

:: Ни өчен без нәкъ менә җиде буын әби-бабайны белергә тиеш?

– Җиде буынны белгәч, без бөтен яклап туганнарыбызны беләбез, исәннәре белән аралашабыз. Халкыбыз юкка гына: «Исәннәрнең – кадерен, үлгәннәрнең каберен бел», – димәгән. Шуңа күрә кем әле җиде әби-бабасын белми – эзләгез, табыгыз. Аннан да күбрәк буынны белә алсаң, тагын да яхшырак. Бу эштә дәүләт архивлары зур ярдәм күрсәтә. Аларга чиксез рәхмәт.

:: Нәселдә бер генә малай калу – нәсел өчен сынау, диләр. Бу чынлап та шулаймы?

– Әби-бабайларыбыз ун, унике, унөчәр бала үстергән. Хәзерге гаиләләрдә исә ике бала булу да – зур шатлык. Нәселдә бер генә малай калу – нәсел өчен сынау, диюләре дә, һәр гаилә күбрәк бала табып үстерергә тырышсын, дигән ният белән әйтелгән. Аллаһы Тәгалә күпме бирә, шуның кадәр алыгыз, балаларны үтермәгез. Аллаһы Тәгалә һәр баланы үз ризыгы белән бирә. Шуңа күрә һәрбер гаилә күпбалалы гаилә булсын иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

НӘСЕЛ ӨЧЕН ДОГА КЫЛУ ТӘРТИБЕ

Аллаһы Тәгалә Корьәни Кәримдә Ибраһим галәйһиссәлләмне мисал итеп китерә. Алар малае Исмәгыйль галәйһиссәлләм белән Кәгъбәне яңарталар һәм Ибраһим галәйһиссәләм шунда: «Ябраббым, минем балаларым шушында синең Кәгъбә янына килеп, дога кылучылар, сиңа сәҗдә кылучылар булсыннар иде», – дип дога кыла. Нәсел өчен дә шушы дога кылына.

:: «Нәсел чистарту» дигән төшенчә дә бар бит әле. Әйтик, таркау гаиләләрдә бөтен туган-тумачаны җыеп, барлап торган бер кеше була. Нәселне чистартып, хак юлга кертеп буламы, әллә Аллаһы Тәгалә ничек язган, шулай дәвам итәчәкме?

– Һәр нәрсә Раббыбыз Аллаһтан. Ләкин рухи яктан тәрбияләп, үгет-нәсыйхәт бирүче кеше дә булырга тиеш. Аксакаллар, акъәбиләр, туганнарны туплап, барлап, берләштереп торучылар һәр нәселдә була. Әлхәмделилла, Аллаһы Тәгаләдән сорасак, нәселне дә чистартып, тайпылганнарны туры юлга кертеп була.

:: Нәсел, нәселдәге фәлән буындагы кеше кешегә энергия биреп тора аламы?

– Энергия, көч-куәт – барысы да Аллаһы Тәгаләдән. Шуңа күрә нәселдән, нәселдәге фәлән кешедән энергия, йә булмаса, нәсел ләгънәте килә ише хорафатларга ышанырга ярамый. Бер-берегезне саклагыз, Аллаһы Тәгаләдән көч-куәтләр сорагыз.

Локман Хәким нәсыйхәтләре

◆Таңда әтәч кычкыргач, йокыннан тор, намазыңны укып, хәләл кәсепкә кереш. Әтәчтән дә ялкау булма. Пәйгамбәребез әйткән: «Сезнең хәерлегез дөньясы дип ахирәтне куймас, ахирәте дип дөньясын куймас, икесен дә тигез күрер һәм башкаларга йөк булмас».

◆Тәүбәңне икенче көнгә калдырма – үлемнең кайчан киләсен белмисең. Гөнаһлы кешенең гөнаһы – гөнаһ кылганнан соң тәүбә кылмыйча, тәүбәсен кичектерүдә. Үлем килгәч, тәүбә капкасы ябыла.

◆Телеңне истигъфарга гадәтләндер. «Әстәгъфируллаһ, Әллаһүммәгъ-фирли»ләрне еш әйт.

◆«Көнгә ким дигәндә 70–100 мәртәбә истигъфар әйтегез» (хәдис). Чынлыкта, Аллаһы Тәгаләнең догаларны кире какмый торган сәгатьләре бар.

◆Белгән гыйлемнәреңне тормышта дөрес итеп кулланырга өйрәнмичә, яңа гыйлем артыннан чапма. Гыйлеме булып та, аны куллана белмәгән кеше китап төягән ишәккә охшый. Ишәк өстендә китап күбәюдән файда юк, ишәкнең йөге генә арта.

◆Дөнья ул – диңгез. Бик күпләр анда батып үлә. Исән каласың килсә, тәкъвалык, канәгатьлек көймәсенә утыр.

ҺӘР ХӘРЕФЕ ШИФАЛЫ

Нидерланд психологы, профессор Ван дер Ховен ачыш ясаган: «Аллаһ» сүзе кешенең калебе генә түгел, сәламәтлеге өчен дә файдалы. шулай дип ышандыра.

Профессор үзенә килгән авырулар белән өч ел тәҗрибә уздырган. Аларның берсе дә мөселман булмый, күпләре хәтта гарәпчә бер сүз дә белми.

Аларга «Аллаһ» сүзен дөрес итеп әйтергә өйрәтәләр. Нәтиҗә искиткеч була, бигрәк тә төшенкелеккә бирелү һәм психик киеренкелектән интегүчеләргә файдалы була ул.

Психолог Ван дер Ховен үзе: «Корьәнне гарәпчә даими укучылар һәртөрле психик авырулардан имин була, чөнки анда «Аллаһ» сүзе күп мәртәбә кабатлана», – ди.

Профессор сүзләренә караганда, «Аллаһ» сүзендәге һәрбер хәреф психик авыруларны дәваларга ярдәм итә. Мәсәлән, «һәмзә» белән «әлиф», сулышны контрольдә тотып, тын юлларының эшчәнлеген яхшырта. «Ләм» сулышны җиңеләйтә. Ахыргы хәреф «һә» үпкә белән йөрәкне тоташтыра. Бу тоташу, үз чиратында, йөрәк тибешен тәртипкә сала.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Мин = милләт

Асыл

– Ягулык салу станциясенә кереп чыгу өчен биш минут та җитсә, электромобильгә заряд җыярга шактый вакыт кирәк. Әнә шуны истән чыгармагыз. Бу яктан шәхси йортта яшәүчеләргә җиңелрәк. Электр станциясен, гомумән, сатып алмасаң да була. Өйдәге гади электр розеткасы аша килгән ток 16 ампер, ягъни сәгатенә 3 кВт тәшкил итә. Электромобильнең батареясы уртача 60 кВт дип алсак, машинага заряд җыеп бетерү өчен якынча 20 сәгать вакыт кирәк булачак. Вакыт кадерлерәк икән, кирәкле «ягулык»ны бер сәгатьтә җыя торган станцияләр дә бар, – ди ул.

Тәҗрибәле йөртүче сүзләренә караганда, электромобильнең батареясы уртача 300 чакрым юлга җитә. Электрокар сатучыларның әлеге санны 400–500 дип күрсәтергә тырышулары-на артык ышанмаска киңәш итте Рөстәм Галимҗанов.

– Әле күптән түгел генә Казан – Болгар автойөрешен үткәрдек. Шул рәвешле, бергәләп вакыт үткәрүдән тыш, электр транспортларының мөмкинлекләрен дә өйрәнәбез. Тәҗрибәдән күренгәнчә, уңайлы шартларда, югары тизлек, кондиционер, музыка белән йөрү теләге зуррак булган саен, электр энергиясе дә күбрәк тотыла. Ничек кенә булмасын, халык электромобильгә күчеп утырачак. Әле берничә ел элек кенә мондый транспорт чарасы белән фанатлар гына кызыксынса, бүген вазгыятьне аңлый торган гади кешеләр электромобиль сайлый. Татарстан заряд станцияләре белән тулысынча тәэмин ителгән. Элек электромобильдә ил буйлап сәяхәт итүчеләр безнең төбәкне урап узарга тырышса, бүген, киресенчә, Татарстан аша йөриләр. Чөнки бездә бөтен шартлар да бар, – ди «Рестарт» җитәкчесе.

Көн кадагында



Киләсе елдан Татарстанда электромобиль хуҗаларын транспорт салымыннан азат итмәкчеләр. Дәүләт Советы депутатлары шушы арада гына шуңа бәйле канун проектын тәкъдим итте. Ташлама биш ел гамәлдә булачак, ә 2029 елдан электрокарда йөрүчеләр транспорт салымы ставкасының яртысын гына түләячәк, дип көтелә. Мондый ташлама илнең күп төбәкләрендә, аерым алганда, Мәскәүдә һәм Мәскәү өлкәсендә, Башкортстанда, Удмуртиядә гамәлдә инде. Әлегә Татарстанда яшәүче электромобиль хуҗалары түләүле машина кую урыннарыннан бушлай файдалана ала. Моның өчен Татарстан Дәүләт автоинспекциясе реестрына кертүләрен сорап, гариза язарга кирәк. Электрокар йөртүчеләр түләүле автомобиль юлларында да бушка йөри алачак дип фаразлана.

ӘҖӘТЛЕНЕҢ ӘҖӘЛЕ

КОЛЛЕКТОРЛАР БУРЫЧЛЫГА КӨН КҮРСӘТМӘСӘ, НИШЛӘРГӘ?

vk.com

Коллектор дигән сүз генә дә күпләрдә шик-курку уятырга мөмкин. Аңлашыла инде: күпчелек очракта куркыту, янау, җәзалау белән эш иткән бу хезмәткәрләрнең әллә ни яхшы даны юк. 2016 елда ук Россиядә коллекторларга шантаж, янау, өзлексез шалтырату һәм бурычлы кешеләргә психологик басым ясау ысулларын тыючы закон кабул ителсә дә, әҗәт йөгеннән генә түгел, акчаны таләп итүчеләрдән дә алҗыган халыкның шикаятьләрен әле дә кабул итәргә һәм тикшерергә туры килә.

Бурыч эче борыч

Хәзерге вакытта Татарстанда 13 коллектор оешмасы эшли. Быелтыр мондый оешмаларның саны 14 иде. Закон кысасында эшли алмагач, бер оешма ябылырга мәҗбүр булган.

Коллекторларның законсыз эш итүләре аркасында приставларга мөрәҗәгать итүчеләр күрсәткече исә мондыйрак: 2021 елда – 733, 2022 елда – 1057. Бу елның гыйнвар – сентябрь аралыгында коллекторларга карата шикаятьләр саны 545кә җиткән. Хәер, узган ел андыйлар күбрәк иде: суд приставларына ул чорда 700гә якын мөрәҗәгать кергән.

Бурычлы кешегә көн күрсәтмәсәләр, нишләргә? Аның хокуклары бармы? Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча дәүләт реестрын алып бару һәм түләү вакыты чыккан бурычны кире кайтаруны хәл итүче юридик затлар эшчәнлегенә контроль бүлеге җитәкчесе Дмитрий Богумель, бар, дип тынычландыра.

Белгеч сүзләренчә, халыктан килгән шикаятьләрнең күпчелеге коллекторларның өзлексез шалтыратуларына, смс-хәбәрләренә, психологик басым ясауга кагылышлы видеоларына бәйле икән.

– Бурычлылар белән ничек эш итәргә икәне 230 номерлы Федераль законның 4 нче маддәсендә аңлатыла, – дип искәртә Дмитрий Богумель. – Шалтырату димәктән, телефоннан шалтырату саны аена сигездән, атнасына – икедән, көненә бердән артырга тиеш түгел. Текст хәбәрләренә килгәндә, тәүлегенә – ике, атнасына – дүрт, аена 16 хаттан да артыграк язарга ярамый. Коллекторлар очрашырга тәкъдим итәргә мөмкин. Андый күрешүләр саны да чикле – атнага бер генә.

Коллекторлар вакыт ягыннан да чикле: алар төнлә яки иртә таңнан шалтыратырга тиеш түгел. Закон буенча, эш көннәрендә 22.00 сәгатьтән 8.00 сәгатькә кадәр, ял һәм бәйрәм көннәрендә 20.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр шалтырату тыела.

Баксаң, җитәкче үзе дә намус кушканча эш итә белмәүче коллекторлар корбаны икән.

– Бер ел буе төнлә телефонга шалтыраттылар. Бер ел буе алай ярамаганын, закон буенча түгеллеген аңлатырга тырыштым. Нәтиҗәдә административ эш ачтык. Бу телефон номерының элеккеге хуҗасы безгә үзе мөрәҗәгать итте, тикшерү уздырып, аны республиканың Арбитраж судына тапшырдык. Банкны җаваплылыкка тарттык. Мине борчыганнары өчен – 10 мең сум, законсыз эш алып барулары өчен 500 мең сум күләмендә штраф салынды, – дип сөйләде ул.

Белгеч тагын бер очракны телгә алды. Вахитов районы судында тикшерелә торган эш бу. Бераү әҗәтләрне бурычлы кешедән генә түгел, ә аның барлык гаилә әгъзаларыннан сорый башлаган. Кыз баласына исә җенси көчләү белән үк янаган. Бу оешманы, билгеле, җаваплылыкка тартып, 1,5 млн сумлык штраф түләргә мәҗбүр иткәннәр.

Дмитрий Богумель штраф күләме хакында да искә төшерде: кемдер коллекторлык эшчәнлеге белән физик зат буларак шөгыльләнә икән, аңа 50000 сумнан 500000 сумга кадәр штраф яный. Юридик затка исә 200000 сумнан 2000000 сумга кадәр штраф каралган.

Белгеч сүзе

Коллекторлар шәхеснең хокукын бозган очракта нишләргә? Аларны да судка биреп буламы? «ВТ» юристы Булат Закировтан шул хакта сораштык.

– Закон нигезендә коллекторларга нәрсә эшләргә ярамый соң? Беренчедән, бурычлы кешегә физик көч куллану яки аны куллану, үтерү яки сәламәтлеккә зыян китерү белән янау; икенчедән, милекне юк итү, җимерү яки зыян китерү белән янау; өченчедән, кешенең тормышы һәм сәламәтлегե өчен куркыныч булган ысулларны куллану; дүртенчедән, бурычлы кешегә һәм башка кешеләргә психологик басым ясарга, бурычлы кешенең һәм башка кешеләрнең намусын һәм дәрәҗәсен түбәнсетүче башка гамәлләр башкарырга. Нинди хокукны бозуларына карап, мөрәҗәгать итү органы да билгеләнә. Әйтик, физик көч куллану, җәзалау яисә үтерү белән янаганда – полициягә, шалтырату кагыйдәләрен бозган очракта – Роскомнадзорга. Искәртеп үтик: коллекторлар эш көннәрендә 08.00дән 22.00гә кадәр һәм ял көннәрендә 09.00дән 20.00гә кадәр генә шалтырата ала. Суд приставлары федераль хезмәтенә исә коллекторларга кагылган теләсә нинди сорау буенча мөрәҗәгать итеп була. Банк, микрофинанс оешмасы тарафыннан бозылган хокукларны Россия Үзәк банкына хәбәр итәргә мөмкин. Башка ведомстволарга мөрәҗәгатьләрегез уңышсыз икән, Россия Прокуратурасына мөрәҗәгать итеп карарга була. Иң мөһиме, шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәнче, сезнең хокукларыгызны бозу турында дәлилләр (фото-видео, диктофон язмалары, телефон сөйләшүләре язмалары, хәбәрләр, хатлар, китерелгән зыянны һәм зыянны теркәү) алырга кирәк, – диде юрист.

Моннан тыш, коллектор, банк, микрокредит оешмаларының законсыз гамәлләре турында **8 (843) 514-92-35** «кайнар элемтә» телефонына шалтыратырга була.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сан

Суд приставлары федераль хезмәте мәгълүматларына караганда, узган елда Россия буенча коллекторларга карата шикаятьләр саны 20 процентка арткан. 2022 елда җәза чарасы сыйфатында билгеләнгән штрафлар күләме 286 миллион сум чамасы тәшкил иткән. Алдагы елдагыга караганда 40 процентка зуррак сан бу. Узган елда түләү вакыты чыккан бурычларны кире кайтаруда хокукларны кысу очраклары буенча суд приставларына 39 мең мөрәҗәгать кергән. Суд приставлары коллекторларга карата административ хокук бозулар турында 5,6 мең эш (2021 елдагы белән чагыштырганда 40 процентка күбрәк) кузгаткан.

Коллекторлар белән ничек аралашырга?

✓Иң беренче чиратта, паникага бирелмәскә. Шалтыраткан хезмәткәрне тыныч кына тыңларга, шалтырату максатын белергә кирәк. Шалтыратучының исемен, вазыйфасын, агентлык атамасын соратып, язып калырга була. Бурыч суммасын белешегез.

✓Профессионаллар сезне куркыту өчен түгел, ә киресенчә, сезнең мәнфәгатьләрне исәпкә алып эш итәчәк – шуны онытмагыз.

✓Кредитор турында мәгълүматны Суд приставлары федераль хезмәтенең ачык реестрыннан белешегез.

✓Борчылмыйча, тыныч кына сөйләшегез. Сезнең төп максат – мәгълүмат туплау.

✓Агентлыклар еш кына бурыч йөген киметү мөмкинлекләре барлыгын әйтә. Мәсәлән, бурыч түләүнең индивидуаль графигы, кичектереп түләү, реструктурлаштыру, башка төр ярдәм чаралары.

✓Коллекторлар төнлә шалтыратып интектерә һәм бу мәсьәләне тыныч кына хәл итеп булмый икән, агентларның закон кысасында эш итмәвен исбатларга ярдәм итәрдәй дәлилләр туплагыз. Ике арадагы сөйләшү яздырылганны хәбәр итегез, шалтыратулар кабул ителгән сәгатьләр турында мәгълүматны саклагыз.

** Казанда хезмәт күрсәтүче коллектор агентлыгы мәгълүматларына таянып.*

БИШ БАЛАСЫН ЮГАЛТКАН ФӘРЗӘНӘ ЗИННУРОВА:

«БАШКА ХӘСРӘТЛӘР КҮРЕРГӘ ЯЗМАСЫН ИДЕ»

Апас районының Югары Акхуҗа авылыннан Фәрзәнә апаны язмыш бик сыный. Алты баласының бишесен, гомер иткән ирен җир куенына сала ул. Йөрәге тулы ачы хәсрәт булса да, күңелен төшерми. Өч оныгы хакына яшәргә көч таба. 67 яшендә өч кызга опекун була. Шушы көннән башлап, сабыйларга әти дә, әни дә, әби дә ул.

Гаилә архивыннан

– Үз хәлемне үзем генә беләм. Әмма зарланасым килми. Аллаһы Тәгалә язмышыма шулай язган икән, нишли алам соң? Беркемгә дә үпкәләп булмый. Һәркем үзенә тиешлесен күрә, – ди Фәрзәнә апа. – Ирем Рафик белән начар яшәмәдек. Тормышта ни генә булса да, уздырып җибәрә белдек. Ачы хәсрәтләр аның да, минем дә сәламәтлегемдә эз калдырды. Ирем белән 4 балабызны җирләдек. 1997 елда Рамилем үлде. 2012 елда кабат кайгы җиле ишек шакыды. Бу юлы Сирин вафат булды. Тагын җиде елдан декабрь аенда ике баламны мәңгелеккә югалттым. 2021 елның 1 декабрендә Марс исемле улым авырып китте. Казанга хастаханәгә илтергә кирәк иде. Кызым Алсу аны озатып йөрде. Тик табиблар аны коткара алмады. 25 декабрь төнендә исә Алсу үзе үлеп китте. «Йөрәк», – диделәр...

Алсуның өч баласы ятим кала. Олы кызы Азалиягә – 14 яшь, уртанчысы Зәринәгә – 8, кечесе Ясминәгә 3 яшь була. Алсу беренче ире үлгәч, тагын кияүгә чыккан була.

– Алсу үлгәч, ире үзенең туган ягына китеп барды. Күп тә үтмәде, аның үлгән хәбәрен җиткерделәр. Шулай итеп, оныкларым өчесе дә тома ятим калды, – дип сөйли Фәрзәнә апа. – Башта аларны ятимнәр йортына аласылар иде. Ничек итеп ул балаларны өйдән җибәрим ди?! Карамасардагы өебездә шартлар уңай түгел, диделәр. Акхуҗа авылындагы кызымның йортына күчендек. Анда тиешле шартлар бар иде. Сабыйлар белән шунда яши башладык. Алар өчесе дә бик елады инде. Бөтенебезгә дә бик авыр булды. Хәзер инде әкренләп Алсусыз тормышка өйрәнеп киләбез, – ди Фәрзәнә апа.

Азалиягә 18 яшь тулган. Апаста техникумда пешекче-кондитерга укый икән. Зәринә быел 7 нчегә, Ясминә 1 нче сыйныфка киткән.

– Әле ярый шушы балаларым бар, дим. 2021 елда инсульт булып, ирем үлеп китте. Бу кайгы да ялгыз йөрмәде. 2022 елда дүртенче улым Фәнис вафат булды. Шушы оныкларыма юанып, хәсрәтемне күтәрә алдым, – ди Фәрзәнә апа. – Авылда эшнең бетәсе юк бит инде аның. Ялгыз интегүемне күреп, мине Фәргать исемле кешегә димләделәр. Ул безгә яшәргә күчте. Бик акыллы кеше. Кызларым бабай дип өзелеп торалар. Заманында дүрт балалы хатынга өйләнеп, шул сабыйларны үзенеке итеп үстергән ул. Тик картлыгында ялгыз калган. Шөкер, хәзер берүзе түгел инде. Миңа да иптәш, терәк әле ул. Шөкер, матур гына яшәп ятабыз.

Фәрзәнә апа кешеләрнең яхшылыгына шакката. Алсуы үлгәч, аңа кемнәр генә килми. Алсуның дусты Альбина Бәшировага да рәхмәтле ул. Альбина Фәрзәнә апаның тормышы хакында башкаларга сөйли. Кызларга ярдәм дә оештыра. Әле менә күптән түгел барысын да Казанга алып барган. Җырчы Венера Шәмиева бу гаиләгә ярдәм итәргә теләвен җиткергән.

– Венера акча бирде, без балаларны мәктәпкә әзерләдек. Бик матур киемнәр алдык. Аннары безне кунак итеп тә җибәрде. Бик сөенеп кайттык. Безне зурлаган өчен Аллаһы Тәгалә үзләренә көтмәгән җирдән сөенеч бирсен, – ди Фәрзәнә апа. – Хәзер бар теләгем – ничек тә авыруларга бирешмичә, сынатмыйча яшәү. Шушы балаларны аякка бастыра алсам иде, дим. 71 нче яшем белән барам бит инде. Һәр бала әти-әниле булып үссен, дип телим. Безнекеләр төсле ятимлек күрмәсеннәр. Баласын югалткан әниләр сабыр итсен. Башкача мөмкин дә түгел! Биш баламны югалтып та, түзәм бит әле. Инде бүтән ачы хәсрәтләр күрергә язмасын!

Гаилә архивыннан

ӘЛЕ ЯРЫЙ УЯНЫП КИТТЕМ...

Ул төнне алар мәңге онытмас. 30 август төнендә Әтнә районының Түбән Бәрәскә авылында гомер итүче Гүзәлия һәм Илфар Исмәгыйлевларның яшәгән өч яклы өйләре, терлекләре, каралты-курасы янып бетә. Әле ярый Гүзәлия ханым көйгән искә уянып китә. Документларын гына алырга өлгерәләр.

– Ике улым да өйләнеп, Казанда яшиләр. Алар кайтып киткән көн иде. Иртәгә эшкә дип, китеп кенә бардылар. Ирем белән 11ләр тирәсендә йокларга яттык. Башка вакыт йоклый алмыйча азаплансам, бу көнне изрәп киткәнмен. Берзаман көйгән искә уянып киттем. Үрмәләп икенче якка чыксам, өйалдында ут күренде, – дип сөйли Гүзәлия апа.

Гомере буе фермада сыер сауган ханымның, салкын тиеп, кан тамырларына зыян килгәч, 2022 елда аягын кисәләр. Без танышканда, протезга ияләнеп килүе, өченче ай инде урамга чыгып йөрүе иде. Эшсез тора алмыйм, аягыма ияләштем, дип җитәкчедән эш сорап килгән иде ул. «Ленин» колхозы җитәкчесе Илгиз Хәйруллинның иңнәреннән сөеп, эшкә чыгарсын, Гүзәлия, хезмәт хакын да арттырып түләрбез, дигәненә үзебез шаһит булдык.

Янгында Гүзәлия ханымның протезына зыян килгән. Эчке яктагы силиконнары янып беткән. Салып куйган җиреннән киярго дә өлгерми ул аларны. Янабыз, Илфар, диюгә, ут тагын да көчлерәк кабына. Аптыраган ир ишекне ачкач, ялкын тагын да дөрли. Илфар абый үзе дә аңышмыйча кала. Өстенә ни кигән, шуның белән ишегалдына чыгып китә. Аяклары белән күмергә басканын да аңламый. Өстендәге киемнәренә ут кабып, тәненең 70 проценты пешә.

– Мин тончыга башлаган идем инде. Түр яктагы ачыла торган тәрәзәгә килеп, бар көчемә: «Илфар!» – дип кычкырдым. Шул тавыш аны да сискәндереп җибәргән. Ул йөгереп килеп, тәрәзәдән мине тартып алды, – ди Гүзәлия ханым.

Илфар абыйны шундук хастаханәгә озаталар. Әтнә табиблары Казанга җибәрә. Әлегә хәле җиңелләрдән түгел. Эчке органнарына зыян килмәсә дә, пешкән җире күп. Ике улы чиратлашып әтиләрен карый. Гүзәлия апа әниләре йортында яшәп тора. Йорт урынын авыл халкы җыештырган.

– Авылдашларыма чиксез рәхмәтле без. Илгиз Хәйруллин иремне хастаханәгә үзе алып барды. «Нәрсә эшлик?» – дип кенә тора. Кешеләр бик ярдәмчел бездә. Ниләр генә китермиләр! Корбан чалып та алып килеп бирделәр. Аларның яхшылыгын күреп күңелем тула, – ди Гүзәлия ханым. – Йортсыз яшәп булмас инде. Йорт-җиребезне төзекләндереп кенә бетергән идек. Лапасларны яңарттык. Тик уттан бернәрсәне алып калып булмады. Алга таба, белмим, нишләрбез. Әлегә Илфарның хәле уңайланмыйча, берни әйтеп булмый. Яңа йорт салыйкмы дип тә уйладык. Авылда буш торучы өйләр дә бар. Әллә шуларны сатып алыйкмы дип тә уйлыйбыз. Тик үз көчебездән генә килмәс инде. Кешеләрдән ярдәм сорамыйча булмас...

Исмәгыйлевлар гаиләсенә булышырга теләүчеләр 89518936023 телефон номеры аша уллары Инсаф Илфар улының банк карталарына акча күчерә ала.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

«Артларыннан калмыйча йөрим»

Әлмәт

Әлмәт районының Яңа Кәшер авылына баргач, ап-ак казлар белән тулган су буена күзебез төште. Нинди ямьле! Авылга үзе бер җанлылык өсти. Саклаучысы да бар. Ул – Лениногорск районындагы Бәкер авылыннан килгән 45 яшьлек Искәндәр Гулов.

Искәндәр бертуган Рәмзия апасының казларын көтәргә июнь аенда ук килгән. Һөнәре буенча – тракторчы. Буш вакытында фермерга барып та хезмәт куя икән. Яз көне тавык-чебешләр дә саткалый. Кыскасы, эшсез тормый. Әлбәттә, казлар көтү дә бушлай түгел. Ашау-эчүдән тыш, көн саен кесәсенә 400 сум керең бара. Үзе әйтмешли, бу акча яшәргә җитә. Гаилә корып караган, әмма барып чыкмаган. Кабат өйләнергә әлегә исәбе юк. «Ялгызлыкка өйрәндем инде», – ди. Әтисе алты ел элек дөнья куйган. Әнисе авырый, аны апасы тәрбияли. Төп нигездә Искәндәр үзе генә яши. Казларны урнаштырып бетергәч, кире туган авылына кайтып китәчәк. Бәкер моннан – 70–80 чакрым тирәсе.

Искәндәр иртәнге сәгать 8дә – су буенда. Ул 350 баш каз өчен җаваплы. Кечке 5кә кадәр көне шулар белән мәш килеп уза. Яңгырына да, эссесенә дә күнеккән. Без килгәндә дә яңгыр сибәләп тора иде. Искәндәрнең моңа исе дә китмәде. «Казларны өйдә ябып тотып булмый. Анда үсми бит алар. Су буенда йөртергә, чирәм ашатырга кирәк. Өйгә кайткач, мичкә ягып, бәрәңге пешерәм. Шул чакта ите дә тәмле була», – ди Искәндәр.

– Казлар тыңлыйлармы? – дип тә сорадык аннан.

– Кулда шалтыравык булса, тыңлыйлар. Булмаса, әллә ни исләре китми. Хәзер авылда сарыклар бетте. Шушы шалтыравыклар белән казларны көтәргә калды. Су буенда чыбыркы күтәреп йөреп булмый. Казларны куркытырга шалтыравык та җитә, – диде ул.

Кулында – бауга бәйләгән тимер капкачлар. Шуны суга аткач, казлар куркып яр читенә чыга. Аннан бауны кире җыеп алырга кирәк. Резин итек киеп, суга чумып, каз куып йөрисе юк. Әмма каз артыннан йөреп аяклары арып бетә, ә каз каңгылдавыннан башы авырта икән. Эре мал көтүне җиңелрәк дип саный ул.

Рәмзия һәм Фаиз Сәгъдәтовлар казларны ун ел элек асрый башлаган. Башта үзләренә ит өчен тотканнар. Сораучылар булгач, ел саен баш санын арттыра барганнар. Ире Фаиз комбайнда эшләгәч, ашатырга азык җитә. Рәмзия ханым исә туй, никах мәҗлесләренә казларны пешереп, ыслап, тозлап сата. Яңа елга кадәр казлары калмый да икән. Алучы булганда, ник асрамаска?

– Башта казлар су буенда үзләре генә йөргәләде. Өченче ел көн саен берсе югала башлады. Елгага чәшкеләр ияләшкән булып чыкты, шулар буа икән. Әрәм хезмәт бит. Казлар тик тормый, кеше капка төпләренә дә баргалый. Берәүнең дә үз тирәсен пычраттырасы килми. Шуңа күрә Искәндәрне чакырттык. Үзебезнең туган булгач, ул – безгә, без аңа гел булышып торабыз, – ди Рәмзия ханым.

Сәрия МИФТАХОВА

Идар Мөхәммәтҗанов

ТРАКТОРЧЫ ИЛГИЗӘ

Актаныш

Өйдә – уңган хуҗабикә, биш бала әнисе, колхозда – алдынгы механизатор. Актаныш районының Суыксу авылында яшәүче Илгизә Габдерәшитова күңеленә хатын-кыз нәфислеген дә, ир-ат көрлеген дә сыйдырган. Хезмәт кенәгәсендә бер генә эш урыны һәм бер генә һөнәр язылган – механизатор. 37 ел комбайн һәм трактор иярләгән көчле хатын-кыз белән яшәү тәме турында сөйләштек.

Техникага мәхәббәт каян килә дисәгез, әтисе дә гомер буе механизатор булган.

– Мин тимер-томыр арасында туган баладыр инде, – дип тәмләп көлеп җибәрде Илгизә апа үзе турында сораша башлагач. – Ике малай арасында көтеп алынган кыз булсам да, кечкенәдән үк техникага бик һәвәс булдым. 4 нче класста ук әткәйнең машинасында йөри идем инде.

Дәрес, мәктәпне тәмамлагач, сатучы булып эшләп ала әле ул. Тик күңеле барыбер техникага тартыла.

– Кибеттәге эшемне ташлап, СПТУга тракторчыга укырга кердем. Ул вакытта бу һөнәргә укучы хатын-кызлар юк иде диярлек. Булса да, бик сирәк иде. Аны тәмамлагач, 1980 нче елларда колхозга эшкә кайттым. Шуннан башлап пенсиягә чыкканчы тракторда эшләдем. Эшемне бик яраткач, башка эш күземә күренмәде дә, кызыксынмадым да, – ди ул.

Әлбәттә инде, «хатын-кыз эшемени инде бу, нигә кирәк ул сиңа бу» дип аптыратучылар да булган. Ләкин ул бервакытта да сер бирмәгән. Матур гына елмайган да: «Әйе, мин шундый!» – дип җавапплый торган булган. Үҗәтлеген, булдыра алуын Илгизә апа еллар һәм сәләте белән раслаган.

– Колхоздагы иң иске «ДТ-75» тракторы минеке иде. Шул иске генә тракторда эшләп тә, 11 ел кыр батыры булып танылдым. Колхозлар беткәч, Әнәккә барып, 10 ел комбайнда эшләп кайттым. Мин бөтен транспортка да «эх!» тә итмичә утыра алам. Самолет белән вертолет бирсәләр, аларын да бер курыкмыйча йөртер идем! Шуңа күрә кушаматым да гомер буе «Терешкова» булды. Транспорт ватылса, гел үзем ремонтладым. Минем өчен тракторны сүтеп җыю берни тормый. Бик авыр әйбер күтәрергә туры килгән очракта гына иремне чакыра идем.

Ире Дилфас абый да алдынгы механизатор икән.

– Ирем миңа охшамаган, тыныч холыклы, басынкы, сабыр кеше. Мин өйдәгесен җайга салган арада, ул тыштагысын эшләп керә, – диде ул ире турында.

Гаилә дигәннән, ут яндырып эшләгән еллар арасында биш бала үстердем, дигәч, әңгәмәдәшебезгә сокланыубыз һәм ихтирамыбыз тагын да артты.

– Барысына да өлгердем. Кайсы балам белән декретта утырдым, кайсы белән юк, – диде ул, тагын бер гаҗәпләндереп. – Биш айлык Ришатым белән дә, тугыз айлык Гөлчәчәгем белән дә эшкә чыгып киткән чаклар булды. Ике балам белән генә декретның ни икәнен сиздем. Иркәләнеп кенә өйдә яту минем холкыма туры килми. «Айт!» дигәнгә «тайт!» дип тордым. Өч балам трактор кабинасында үсте. Минем янда утырып йөрү алар өчен сөенеч иде. Төрле чаклар булды, авыры да, җиңеле дә. Тик эше рәхәт булгач, авыры сизелмәде дә. Эштән кайтышлый ук утын күтәреп кереп, мич ягып, йорт җылыта торган, суны әллә кайдан ташып торган заманалар иде бит. Балалар үсә төшкәч, без кайтуга мич ягып, ипи салып, аш пешереп, малларны карап куя торган булдылар. Минем өчен иң рәхәт чаклар шул иде.

Нинди генә шартларда эшләсә дә, куелган норманы үтәргә тырышкан Илгизә апа. Иске комбайнда да яңа «Акрос» комбайннары белән бертигез эшләгән чакларын сагынып искә алды.

– Аларга – 14, безгә 7 тонна ашлык сугу бурычы куела иде. Мин шуны 16 тонна итеп эшли идем. Кеше туктаганда да мин ярты пакус бара идем әле, – диде ул.

Холкымда ир-ат сыйфатлары күп, дисә дә, әни, хуҗабикә вазыйфаларын да бик оста булдыра торган ханым булып чыкты Илгизә апа. Йортындагы кырык-маса-кырык төрле хатын-кыз мәшәкатен башкарырга да, биш баласын карарга да, ирләр эшен эшләргә дә никадәр көч һәм тәвәккәллек каян килгән диген үзенә!



Зөлфия Халиуллина

– Минем эшләмәгән эшем юк, – ди үзе дә. – Бер эшне дә кешедән эшләткәнем юк. Тегүен дә тегәм, чигүен дә чигәм. Балаларыма киемне үзем тегем кигерттем. Чәкчәк, торт, бизеләрны туганнарыма да пешереп бирәм әле. Бернигә дә иренмим, шул ягым әйбәт. Эшләгән вакытларда аз йоклый идем. Нибары 3–4 сәгать. Миңа шул да җитте.

Эшнең сөяк сындырганы юк. Илгизә апа да, ире Дилфас абый да шулай уйлый. Балаларын да үзләре үрнәгендә тәрбияләгәннәр. Көне-төне эштә булсалар да, биш балаларына да югары белем биргәннәр Габдерәшитовлар. Олы кызлары Илсөяр белән Гөлчәчәк – укытучы, Дилшат белән Ришат «Челны-бройлер» компаниясендә эшли, төпчекләре Азат – көрәшче.

– Пенсиягә чыккач, бер көн дә эшләмәдем. Яшьләргә дә ирек бирергә кирәк. Алайса: «Минем урынга кеше таба алмыйлар», – дип эшкә ябышып ятучылар да бар. Алай түгел, эштән туктаган бөтен кешенең дә урынына кеше табыла ул. Мәсәлән, мин иң иске «Дон 1500» комбайнын куеп чыгып киттем, хәтта анда эшләргә дә кеше табылды. Иске дип тә тормадылар. Кеше пенсиягә чыга икән, аның кадерле чагында китүе яхшы. Мин дә булдыра алам әле. 63 яшь булуына карамастан, бүген дә комбайнын да иярли, «К-700» тракторына да утыра алам. Әле энергиям җитә!

Хәзер үз хуҗалыкларында җир җимертеп, дөнья куып яши алар. Тугыз гектар пай җирләрендә үлән үстерәләр. Теләсә нинди техникага утырып, теләсә нинди эш башкарырга сәләтле ханым өчен иң рәхәте дә әнә шунда.

– Әллә нинди зур дәрәҗәләргә ирешмәсәм дә, гомерем буе үзем теләгән эштә эшләдем, – ди ул чын күңелдән. – Җәфаланып түгел, чын күңелдән яратып. Тик торганнан гына баш иярргә яратмыйм, үз сүземне үзем әйтеп, нинди генә хәлдә дә үз фикеремне белдерергә тырышып яшәвем белән бәхетле мин. Бөтен байлыгым гаиләм – биш балам, уноч оныгым һәм эшем булды!

Зөһрә САДЫЙКОВА

Авыл язмалары

САВАПЛЫ БИЗНЕС

Марат КӘБИРОВ

Иртән торып ихатасына чыгуга, Фатыйма карчык койма буендарак бик мескен кыяфәттә бөршәеп торган песи баласын күреп ала. Кап-кара шундый, күкрәгендә генә уч яссысы хәтле агы бар. Матур. Песи балалары гына шулай бугай инде ул, аларның мескенлеге дә һәрвакыт матурлык кебек күренә. Әби кеше нечкә күңелле була бит инде, күрше хатыны хәергә керткән сөтен чыгарып бирә бу моңа, башыннан сыйпап иркәләп ала.

Ялгыз тормышына бик әйбәт иптәш булыр иде дә… Ана песи икән шул, балаласа, ничек итәрсең… Аннан соң, карчык ел саен балаларында, шәһәргә китеп кышлый. Үзе юкта песие нишләр, аны да иярпеп йөреп булмас. Песи баласы ничек кенә матур тоелмасын, ияләштерергә ярамый. Бер ияләшсәң, кызганыч була башлый әле ул, аерыласы килми башлый.

Тик күз алдында булгач, ашатмый да кала алмыйсың инде. Аллага шөкер, муллык заманы, ризык накыс түгел, ни теләсәң, шул бар. Әби сыйлый инде песи баласын. Ә теге күнегә төшә, әби дә ихатага чыккан саен карашлары белән аны эзли.

Шулай узган ике-өч көн эчендә югары очның Зарифы керә моңа. Берәр эшкә ялланып эшләргә ниятләп йөри инде, аз-маз акча юнәтеп, тамак ягын хәстәрләргә тели. Ә аның тамагына сыек ризык кирәк. Булса булыр дип, әби ике йөз тәңкәсен тоттыра да песине сыер фермасына илтергә куша. Анда җылы да, савымчылар да сөт биреп тора, күсе-фәләне дә җитәрлек. Хуҗасыз песиләр оҗмахы шунда инде, кыскасы.

Зариф алып китә песи баласын. Әби котылып, җиңел сулап кала. Тик озакка түгел, берничә көн үтүгә, ихатасында тагын бер песи баласы пәйда була. Монысы ала төстә. Берничә көн ашаткач, тагын теге Зариф килеп керә. Әби тагын шул ук йомышын куша, шул ук акчасын түли. Монысын озатып беркадәр вакыт узуга, ихатасында соры песи пәйда була…

Кешесе дә әллә ничек бит аның хәзер, артык-портык песиләрен фермага илтсәләр дә булыр иде, юк, алай итмиләр, чыгып йөри алмый торган карт-корының ишегалдына ыргытып китәләр. Телиме-теләмиме, ашата инде карт кеше теге песине, я берәрсенә кушып фермага илттерә.

Түбән оч Хәдичә карчыкта да шундыйрак хәл икән. Ул бер тапкыр ала песиен, бер кара песиен илттергән. Ә Гайшә карчыкта башта соры песи пәйда булган, аннан соң ала, аннан кара песи. Шул рәвешле әбиләрнең үзләренә дә, санаулы пенсия акчаларына да тынгылык юк. Бер-берсенең хәлен дә белмиләр. «Ватсап»тан сөйләшергә өйрәнмәгәннәр, биләмгә йөрерлек хәлләре юк. Сирәк-мирәк очрашкан вакытларында да песиләр турында сөйләшеп сүз әрәм итмиләр, хатирәләре дә, моң-зарлары да җитәрлек. Ә песиләр килә тора, китә тора…

Әбиләрнең хәлен Зариф кына белә. Кагылып чыккан чакларында авыл яңалыкларын сөйләп ала, илдәге вакыйгаларны аңлата. Тик песиләр турында ул да бер сүз әйтми. Ярамый алай итәргә. Ул керә, хәл белә, йомышларын үти. Шул рәвешле көн саен авылны бер урап чыга да, өенә кайтып, шакмаклы дәфтәренә нәрсәдер яза. Язып барырга кирәк барысын да. Бутарга ярамый.

Кара песи Фатыйма әбидә булды, Хәдичә карчыкта булды, Гайшә абыстайда булды… Сәмига түтидә, Фәйрүзә корткада… Тагын биш җирдә… Җәмгысы кара песидән ике мең сум табыш килгән. Ала песидән – ике ярым, соры песидән – мең сигез йөз сум.

Боларның барысын да язып барырга кирәк, бутарга ярамый, югыйсә икенче керүендә: «Әнә син илткән теге песи кире кайткан», – дип әйтүләре бар. Анда инде акча сорап булмаячак.

Уңганлыгы, акылы, башка асыл сыйфатлары белән артык аерылып тормаса да, Зариф үзенә әйбәт бизнес уйлап тапкан. Ул үз абзарында туган песи балаларын әле бер, әле икенче карчыкка күчереп йөртеп акча эшли. Савабы да бардыр әле аның. Акча да бирәләр, рәхмәт тә укып калалар.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык алтынчы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык алтынчы утырышын 2023 елның 14 сентябрендә 10 сәгатьтә Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 7 сентябре
№ 2090-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык алтынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәлә турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык алтынчы утырышы каравына «Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республиканың эчке һәм тышкы хәле турында еллык юлламасы» мәсьәләсен кертергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 7 сентябре
№ 2091-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык алтынчы утырышын телевидение һәм радио аша туры-дан-туры трансляцияләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2023 елның 14 сентябрендәге кырык алтынчы утырышын телевидение һәм радио аша туры-дан-туры трансляцияләүне оештырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 7 сентябре
№ 2092-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык җиденче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык җиденче утырышын 2023 елның 14 сентябрендә 12 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 7 сентябре
№ 2094-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык җиденче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык җиденче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 459-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
3. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 456-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» 454-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 462-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 467-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 442-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
8. «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 15 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 464-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында» 458-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 460-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 465-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 466-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
13. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 461-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. Югары белем бирү мәгариф оешмаларының спорт-савыктыру лагерьларын реконструкцияләү турында Россия Федерациясе фән һәм югары белем министры В.Н. Фальковка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында.
15. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның сентябренә кадәр чордагы эше турында хисабы.
16. 2022 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады.
17. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.45 статьясына үзгәреш кертү хакында» 406657-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт сере булган белешмәләрне үз эченә алган мәгълүматны саклау өлкәсендә административ хокук бозулар хакында эшләрне карау вәкаләтләрен төгәлләштерү турында).
18. Хөкүмәт сәгате: «Матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру барышы хакында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 7 сентябре
№ 2095-VI ДС

Саннар фокусы

1 Унга кадәр бер санны сайла да уеңда тот.
2 Шушы санга тагын шулхәтлене үк куш.
3 Килеп чыккан санны дүрткә тапкырла.
4 Иң башта сайлаган санга бүл.

8 саны килеп чыктымы? Ничек белдең дип сорама, үзем дә белмим.

Әз-мәз мәзәк

Театрда:
– Ни өчен сәхнәдә мылтык эленеп тора?
– Режиссерның холкы бик начар, диләр.

* * *

– Бигрәк озак саныйсың инде акчаны!
– Яшел акча белән биргән булсаң, 100 тапкыр тизрәк санар идем.

* * *

Менә син эштә утырасың, ә синә әҗәте булган танышың быел инде икенче тапкыр диңгезгә бара.

* * *

Мин хәзер шундый яшькә җиттем, минем чордаш егет-кызларның башларында бер генә уй: үз фатирыңны булдыру.



Сканворд җаваплары

Горизонталь: яла, Аймәт, алу, иялек, ру, Ост, Болак, ант, Биг, Ра, тавышы, Әни, туташ, атаман, улы, Аулак, баян, дымлылык, Мио, Ла, ук, акыру, Апаз, яр, сынчы, Ли, ЛОР, ми, Коля, аба, ре, Ну, Каравай, карчыга, үлеш, Аида, Ләйсәнә, гер, чыктым, Марс.

Вертикаль: ОРТ, Дуслык, саулык, ярар, Таулар, башлык, ары, Закиров, ылыс, егылу, яулык, ырым, ча, әмәл, аш, Акунин, айгыр, елкы, унисекс, ятак, алачык, дәрт, балта, октан, Апуш, Акмулла, Әхми, тәм, иярү, Набоа, ал, бина, Аве, яланбаш, Гөлназ, ай..

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Беләсең килсә...

1 Хаганта ул нәрсә сорты?

а) алма;
б) кыяр;
в) слива.

2 Сөембикә манарасы эчтән нинди төстә?

а) кызыл;
б) ак;
в) кара.

3 Кузбасс дип кайсы якны атыйлар?

а) Кемерово;
б) Барнаул;
в) Чита.

4 Россия Федерациясенең Федераль Җыелышына әлеге орган керми:

а) Федерация Советы;
б) Дәүләт Советы;
в) Дәүләт Думасы.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. а); 4. б).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14047 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 325

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+